МАЛ ХӘЛЕ

Татарстанда ветеринария тармагында хәл итәсе мәсьәләләр күп

> 2

ЗИНАИДА БУШУЕВА:

«Ленинград блокадасы өзелгәнгә 80 ел булса да, ул фаҗига онытылмый»

> 3

ЯНТЫК ЛОМОНОСОВЫ

76 яшьлек инженер Рафаэль Кушминны күптән түгел кабат пионерга алганнар

> 7

МИЛЛИ АККОРД

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турындагы махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 13 (28980) | Шимбә | 28 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИКЕГЕЗ ДӘ БЕРТИГЕЗ

«АЛДЫНГЫЛАР ХӘРӘКӘТЕ» КИЛӘЧӘК БУЫНГА НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘЧӘК?

Тәрбия

Ватанны яратырга, Кеше булырга, бергә булырга, хәрәкәттә булырга, беренче булырга. Узган ел оешкан «Алдынгылар хәрәкәте» киләчәк буынны шушы кыйммәтләргә нигезләнеп тәрбияләргә җыена. Бу хәрәкәт кемнәр өчен? Аның әһәмияте нидә? «Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы төбәк бүлеге советының беренче утырышында шул турыда сөйләштеләр.

vk.com

Билгеле булганча, «Алдынгылар хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәте Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә узган ел оешты. Яңа хәрәкәт бөтен ил яшьләрен бер йодрыкка тупларга тиеш. Татарстанда бу эшне зур ышаныч белән Татарстан Президенты ярдәмчесе Тимур Сөләймановка тапшырдылар.

– Хәрәкәт эшендә балалар һәм яшьләр турыдан-туры катнашачак. Алар кечкенәдән үк үзләрен бу хәрәкәтнең бер өлеше итеп тоярга тиеш, – диде «Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстандагы төбәк бүлеге советы рәисе Тимур Сөләйманов. – Әлеге хәрәкәт киң катлау балалар һәм яшьләрне берләштерәчәк. Кабатлап әйтәм: актив балаларны гына түгел, ә барысын да. Монда аларның һәркайсы күңеленә хуш килгән, кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль табарга тиеш. Шул рәвешле без балалар һәм яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итәчәкбез.

Берәү дә читтә калырга тиеш түгел. Тимур Сөләйманов сүзләренә караганда, республиканың һәр районында иҗтимагый штаблар, ә мәктәпләрдә, көллиятләрдә һәм башка уку йортларында махсус клублар оештырылачак.

– Хәзерге вакытта «Алдынгылар хәрәкәте» ярдәме белән бөтен илдә битараф булмаган педагоглар һәм остазлар, балалар һәм яшьләрне берләштерә торган зур бер система формалаша. Шунысы мөһим: бу хәрәкәт – моңа кадәр балалар һәм яшьләр белән эшләүче башка хәрәкәтләр һәм оешмаларның көндәше түгел, ә аларны берләштерүче, – диде ул.

Татарстан Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары Марат Хисамиев хәрәкәтнең берләштерү функциясенә аерым басым ясады.

– Моңа кадәр эшләп килгән оешма һәм хәрәкәтләр җитәрлек булган булса, яңа хәрәкәт барлыкка килмәс иде. «Алдынгылар хәрәкәте» аларның эшчәнлеген тагын да куәтләп җибәрәчәк, әмма берсен дә алыштырмаячак, – дип тәгаенләде ул.

Татарстанда «Алдынгылар хәрәкәте» 13 юнәлештә эшләячәк. Алар – мәгариф, фән, хезмәт һәм һөнәр, мәдәният һәм сәнгать, ирекләләр, ватанпәрвәрлек, спорт, сәламәт яшәү рәвеше, медиа, дипломатия һәм халыкара мөнәсәбәтләр, экология, туризм, туган тел, милли мәдәният һәм традицияләр.

Ике канат

Тимур Сөләйманов сүзләре белән әйтсәк, «Алдынгылар хәрәкәте»нең ике канаты һәм төп хезмәттәшләре – Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Яшьләр эшләре министрлыгы. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин фикеренчә, төп бурыч – илебездә яшәүче балаларның, яшьләрнең, укытучыларның, әти-әниләрнең, гомумән, җәмгыятьнең илдә барган вакыйгаларга карашын үзгәртү.

– Идеологиясез узган 30 елның нәтиҗәсе нинди булуын күрәбез. Яшь буын тәрбия алмады, дип әйтәсем килми. Әмма нәкъ менә дәүләт дәрәҗәсендәге, шул ук вакытта балаларны да, әти-әниләрне дә, белем бирү системасын һәм башкасын да колачлаучы хәрәкәт бик вакытлы төзелде. Әйткәнемчә, ул бик зур катлауны колачлый. Әмма ул ихтыяри булырга тиеш. Инде хәзердән үк әти-әниләр һәм укытучылар арасында бу җәһәттән кайгыручылар бар. Без монда берәүне дә мәҗбүриләп китерә алмыйбыз һәм тиеш тә түгел. Ә менә яшь буынны кызыксындыру чараларын булдыру – безнең кулда, – диде ул. – Билгеле, бу хәрәкәтнең нәтиҗәсен бүген-иртәгә генә күрү – мөмкин хәл түгел. Бүген без киләчәкне кайгыртып эшлибез.

Бу сүзләрне яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков та куәтләде.

– Татарстанның яшь буын белән эшләүдә шактый тирән һәм уңышлы тәҗрибәсе бар. Шушы тәҗрибәне туплап, ике зур вектор – белем бирү системасы һәм яшьләр белән эшләү системасын берләштереп эшләргә кирәк булачак, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Тимур Сөләйманов сүзләренә караганда, «Алдынгылар хәрәкәте»нең төп аудиториясе – 4 яшьтән алып 22 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр. Ләкин хәрәкәттә катнашучылар, яшькә бәйле үзенчәлекләрдән чыгып, берничә төркемгә бүленәчәк. Яшенә карап, сүз һәм фикер җиткерүнең юллары да төрле булачак. Әйтик, 4–7 яшьлекләр өчен ул – мультфильмнар, төрле уеннар һәм уенчыклар, җырлар һ.б. булса, 16–18 яшьлекләр өчен – кино, интернет, блогерлар, музыка һ.б.

Максатка ирешелгән

Узган елда Татарстан илкүләм проектларны гамәлгә ашыру буенча барлык максатчан күрсәткечләргә ирешкән. Республика 13 илкүләм проектны (49 төбәк проектын үз эченә ала) хәл итүдә катнашкан. Аларны тормышка ашыру өчен 43,7 миллиард сум тотылган. Барлык районнарда социаль объектлар төзү эшләре алып барылган, мәгариф һәм медицина оешмаларының матди-техник базасы яхшыртылган. Моннан тыш эшмәкәрләргә ярдәм ителгән, балалы гаиләләргә социаль түләүләр вакытында бирелгән, төрле категориядәге кешеләр яңа һөнәрләргә өйрәтелгән.

2022 елда илкүләм проект акчасы хисабына барлыгы 228 объект төзекләндерелгән. Шулай итеп, планда каралган барлык чараларны гамәлгә ашыру билгеләнгән барлык социаль-икътисадый күрсәткечләргә ирешү мөмкинлеге биргән. Әйтик, 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларның 85,35 проценты өстәмә белем бирүгә җәлеп ителгән, яраксызга әйләнгән торак фондының 16,15 мең кв. м мәйданында яшәүчеләр яңа торакка күчерелгән, шәһәр юлларының 83,19 проценты нормативта каралган хәлгә китерелгән, үзәкләштерелгән чиста су белән тәэмин итү системасына тоташтырылучыларның өлеше 94,2 процентка җиткерелгән.

Юлга – миллиардлар

Быел Татарстанда юл эшләренә барлыгы 47,2 миллиард сум акча бүлеп бирелә. Республика Хөкүмәте тиешле программаларны раслаган. Карарга Премьер-министр Алексей Песошин кул куйган да инде.

Шулай итеп, гомуми файдаланудагы юл эшләренә бюджеттан 17,5 миллиард сум юллана. Казан агломерациясенең (аңа Казаннан тыш, Яшел Үзән һәм 6 район керә) транспорт инфраструктурасын үстерүгә федераль бюджеттан – 1,3 миллиард сум һәм республика бюджетыннан 2 миллиард сум бирелә. Чаллы агломерациясендәге эшләргә – 1,3 миллиард сум, Түбән Камага 480 миллион сум каралган.

Төбәк һәм муниципаль әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә – 1,9 миллиард сум, авылларга, авыл хуҗалыгы производстволарына илтүче юллар төзү һәм реконструкцияләүгә 802 миллион сум тәгаенләнә. Дәүләт-хосусый партнерлык нигезендә юлларны үстерү программасы буенча 16,6 миллиард сум каралган.

Агуланганнар

Узган елда Татарстанда 609 кеше хәмердән агуланган (100 мең кешегә 15,6 очрак туры килә). 2021 елдагыга (100 мең кешегә – 17,8) караганда 12 процентка кимрәк бу. 218 кеше агуланып үлгән.

Шул ук вакытта балалар арасында агуланучылар күбәйгән: 2021 елда шундый 29 очрак теркәлсә, узган елда бу сан 39га җиткән. Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Юлия Булатова әйтүенчә, 1 үлем очрагы булган: Бөгелмә районында 14 яшьлек кыз техник спирттан агуланып үлгән. Үсмерләр арасында агуланучылар кимегән: 32 очрак (2021 елда – 40). Антирейтингта Чаллы беренче урынга чыккан. Биредә узган елда балалар һәм үсмерләр арасында 27 агулану очрагы теркәлгән (2021 елда – 26). Икенче урында – Казан (2022 елда – 17, 2021 елда – 22 очрак).

Сәламәтлек

Ковид та, грипп та янәшә

Гыйнвар аенда Татарстанда коронавирус белән авыручылар саны, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 34 процентка кимегән. Шулай да, тынычланырга иртәрәк, ди белгечләр. Ник дигәндә, Татарстанда өч көн рәттән инде ковид йоктыручылар саны арта бара.

Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина хәбәр итте. Соңгы бер тәүлек эчендә республикада коронавирус йоктыруның 68 очрагы теркәлгән. Бу, алдагы тәүлек белән чагыштырганда, өч очракка күбрәк.

Авдонина сүзләренә караганда, коронавирус хәзер күбрәк гадәти ОРВИ рәвешендә уза. Ул үзен бернинди билгеләр аша белгертмичә, кеше аны аягөсте генә дә үткәреп җибәрергә мөмкин.

– Быел коронавирус йоктыручылар арасында ковидның, нигездә, «омикрон» штаммы очрый. «Дельта» штаммы хәзер бөтенләй юк диярлек. Ара-тирә коронавирусның «кентавр», «цербер» штаммнары очрап куя, – ди Авдонина.

Узып баручы атнада Татарстанда 18 меңнән артык кеше грипп һәм кискен сулыш юллары инфекциясен йоктырган. Бу, алдагы атна белән чагыштырганда, 9 процентка азрак. Авырып киткән һәр ике кешенең берсендә дуңгыз гриппы ачыкланган.

– Халык арасында вируслар әйләнешен күзәтү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, грипп вирусы йоктыручылар саны артканнан-арта бара. Гыйнварның беренче атнасында ул 87 процентны тәшкил иткән булса, узган атнада инде 90 процентка җитте, – ди белгечләр.

Республикада грипптан үлем-китем очраклары теркәлмәгән. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков фикеренчә, бу уңайдан куркырга җирлек юк. «Без әлеге эпидемиянең иң югары ноктасын уздык инде. Киләчәктә ОРВИ һәм гриппның яңа дулкыннары булачак дип тә әйтә алмыйбыз», – ди ул.

Шулай да белгечләр бүген барлык саклык чараларын үтәргә киңәш итә. Инде өч елдан бирле язылмаган канунга әйләнгән битлек кию, урамнан кергәч, кулларны, битне сабынлап юу, кеше күп җыелган урыннарга чыкмаска тырышу кебек кагыйдәләрне үтәргә куша алар. Ник дигәндә, бүген республикада берьюлы грипп һәм коронавирус белән авыручылар да очрый. Белгечләр әйтүенчә, иммунитеты төшкән кешеләр күбрәк шул хәлдә кала.

Сүз уңаеннан, бүген республикада коронавирус белән авыручылар өчен билгеләнгән ятак урыннарның 10–15 проценты буш. Хәзерге вакытта республика күләмендә барлыгы 17 вакытлыча инфекция хастаханәсе эшләп килә.

– Ковид йоктыручылар арасында авыр хәлдәгеләре дә бар, билгеле. Әмма бу сан чир иң нык котырган чордагы күрсәткечләр белән чагыштырырлык түгел, – ди Жаворонков.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Дмитрий РОМАНОВ, «Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» ассоциациясе башкарма директоры:

Кешеләр үз хокукларын белеп бетерми. Бу җәһәттән фатирларда, йортларда яшәүчеләрнең бары тик 1–2 проценты гына активлык күрсәтә. Бүген күпкатлы йортларда уза торган җыелышлар, кызганычка, аз нәтиҗә бирә. Торак кодексы барлык мәсьәләләрне хәл итүне милек хуҗалары җилкәсенә йөкли.

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТЛЕК

«Инвитро» компаниясе әзерләгән сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, узган ел Россиядә яшәүчеләрнең сәламәтлеккә тотыла торган чыгымнары 72 процентка арткан.

ТӨП СӘБӘПЛӘР:

49% >> сәламәтлек начараю

25,1% >> профилактика чаралары күрү

18% >>дару һәм медицина хезмәтләренә бәя арту

Озын ялда – Казанга

Казан февраль аендагы озын ялларда туристлар өчен иң популяр шәһәрләр өчлегенә кергән. Татарстан башкаласы 23–26 февральгә MTC Travel и Bronevik.com сервисларында броньланган торак саны буенча икенче урынга чыккан.

Беренче урында – Санкт-Петербург. Төньяк башкала кунакханәсендә яшәү бәясе тәүлегенә уртача 3800 сум тәшкил итә. Казанда һәм Ярославльдә (3 урын) яшәү бәясе – 6000 сум чамасы. Февраль ялларында сәяхәт өчен иң шәп шәһәрләр бишлеген Мәскәү түгәрәкләп куйган. Биредәге кунакханәләрдә тәүлегенә уртача 4600 сум түлисе.

Россия эчендәге шәһәрләр арасында иң арзанлы ял – Ростов-Дон, Самара һәм Томскида (тәүлегенә уртача 2800 сум). Туристларның күпчелеге февраль ялларына өчен кунакханәне ике көнгә броньлаган.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Вәхшилектә чама калмаса...

Бары кайсыдыр милләт вәкиле булган өчен генә санаулы вакыт аралыгында юк ителгән берничә миллион кеше хакында ишеткәнегез булдымы сезнең? Әллә кайсы ерак дәверләрдә түгел, әле узган гасыр уртасында гына. Ихтимал, «холокост» дигән сүзне ишеткән җәһәттә дә, 4–5 ел эчендә планлы рәвештә кыелган 6 миллион (!) җан, системага салынган үтерешләр турында һәркем дә белеп бетермидер. Язма – нәкъ менә «холокост» дип аталган фаҗига хакында. Чөнки кичәге дата, ягъни 27 гыйнвар шул явызлык корбаннарын искә алу көне булды.

Кешелекнең берничә мең елга сузылган тарихында дәвамлы геноцидлар, этноцидлар, башка сыймас бүтән олы җинаятьләр күзәтелмәгән түгел, күзәтелгән. Нацистларның яһүд милләтеннән булган кешеләрне, аерым алганда, аларның Европа кыйтгасында яшәгәннәрен эзлекле рәвештә үтереп килүе – моннан сиксән ел элек кенә кылынган иң масштаблы вәхшәт һәм геноцид. Фашизм эшләгән кабахәтлекләр арасында әлеге җинаять аерым урын алып тора.

Дәүләтсез милләтләр дәүләтсезлек китергән михнәтләр белән бәхетсез. Узган гасырның утызынчы еллар азагы, кырыгынчы еллар башында «Израиль» дигән илнең әле әсәре дә булмый. Бөтен дөнья буенча сибелгән яһүдләр Германиядә дә, нацистлар басып алган, алачак башка илләрдә, мәсәлән, Польшада, СССРда, Румыниядә, башка тарафларда үз җайларына күпләп яшәп ята. Бөтендөнья яһүд конгрессы китергән саннарга караганда, сугыш алды елларындагы 16,6 миллион яһүднең 10 миллионнан артыгы Европада гомер кичергәне билгеле. Тоташ җәбер-золымнар башланганчы, Европа яһүдләре, титуллы милләтләрнең кырынрак карашын тойган хәлдә дә, алай начар яшәмәгән. Ул милләткә хас гыйлемлелек, үткерлек, үҗәтлек, үзара ярдәмләшү кебек сыйфатлар, иленә, җиренә карамастан, үз нәтиҗәсен биреп торган. Кайчакларда хәтта артыгы белән: эре банкирлар, предприятие хуҗалары, дәрәҗәле коммерсантлар яһүд милләте вәкилләре арасында күбрәк тә күзәтелгән.

Германиядә властька Гитлер килгәннән соң хәл кискен үзгәрә. Язуларынча, фюрернең дуамал башына, хакимияткә килгәнче үк, яһүдләрнең читләр канын суырып, читләр хисабына яшәүче паразит халык булуы турында антисемитизмның иң реакцион чагылышы булган фикер инде кереп урнашкан була. Катнаш никахлар төзеп, алман милләтенең чисталыгын юкка чыгаручылар, кан бутаучылар да шулар икән бит. Немецны узып, яхшы тормыш-көнкүреш көйли белгәннәр дә, рибачылыкны үз итеп, һавадан акча ясаган, шул юл белән башкаларны фәкыйрьлектә тотучылар да – Муса-Моисей уллары яһүдләр икән. Гомумән, Җирдәге иң югары сортлы милләт – ариецлар янәшәсендә яшәп, алардан акыллы, уңган, уңышлы булуны – андый оятсызлыкны – аларга күпме кичереп килергә мөмкин? Бигрәк тә титуллы халыкка авыр вакытларда...

Инде күптәннән китап киштәмдә Иоахим Фест исемле авторның өч томлык китабы ята. «Гитлер» дигән албастының яралу, немец милләтен коточкыч җинаятьләргә тарту – 65 миллион кешенең башын ашаган Икенче Бөтендөня сугышын башлау – сәбәпләрен фәнни хезмәт рәвешендә бәян иткән ул. Анда шундый юллар бар: «Фюрерлар теге яки бу халыкның мессия, коткаручы көтүе аркасында туа. Андыйлар, аңлаешлы идеология – милләтнең тирәндә яткан мин-минлегенә тиярлек, шуны өскә калкытып чыгарырлык теория тудырып, аның башкалардан өстенлеген раслый, массаларны шуңа ышандыра да исертелгән халыкны соңыннан теләсә нинди җинаятькә этәрә».

Немец халкы, дөньяга күпме даһиларны биргән бөек милләт ни өчен, нинди сәбәпләр аркасында коткаручы көткән соң? Ни өчен милләтне күпме дәверләр янәшә яшәгән халыктан – яһүдләрдән дә коткарырга кирәк булган? Биредә барысы да Беренче Бөтендөнья сугышына, Германиянең андагы җиңелүенә, илне күп нәрсәләрдән тыйган хурлыклы Версаль килешүенә, фюрерның гына түгел, немец халкының да уй төпкелендә яткан реваншка, яңадан «кеше булу» теләгенә барып тоташа. Фюрер җиңелүдә яһүдләр өлешен дә күрә. Имеш, ул акча коллары, төгәлрәге – корал, башка төрле сугыш кирәк-яраклары җитештерүче яһүд фабрикантлары бәрелешләр иң кызган вакытларда үз продукцияләренә әледән-әле бәя арттырып торган. Баш редакторлары шул милләт вәкиле булган газеталар патриотик рухны сакламаган.

Тоталитар дәүләткә тышкы дошман гына түгел, аның эчкесе дә бик кирәк – антисемитизм шушы һәм башка күпсанлы ялалар аркасында нацизмның состав өлешенә әйләнә дә инде. Баштагы еллардагы чикләү, хокуксызлык 1942 елдан соң, басып алган бөтен территорияләрдә «Яһүд мәсьәләсен ахыргача хәл итү» («Окончателное решение еврейского вопроса») доктринасына барып тоташа – зур шәһәрләрдәге яһүд геттоларына җыйган халыкны шул милләт вәкилләрен юк итү өчен махсус төзелгән концлагерьларга озатулар китә, крематорийлар эшли башлый...

«Уңышларны кичермиләр» («Успехов не прощают») – кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә андый күңелсез күренеш очрап тора. Ике мең ел буе барган дәүләтсезлектә яһүд халкы, юкка чыкмау гына түгел, шул дәүләтсезлек даими китереп торган кагуларга да көч кулланмыйча каршы торырга, үз дигәнен эшләргә өйрәнгән. Егерме гасыр буе үзен саклап килә алган, ул гынамы, җайлашуда бар булган башка халыкларны уздырган, кыенлыклар чыныктырган, кайда яшәвенә карамастан, уңышлы була белгән бүтән кавем Җир йөзендә юк. Әйе, күп ил-җирләрдә аларның яши белүен, уңышларын чыннан да кичермәгәннәр, каныгып торганнар. Россиядә дә революциягә чаклы яһүд погромнары еш кабатланган, «бей жидов!» өндәве ишетелгәләп торган. Башкалаларда, кайбер зур шәһәрләрдә яшәргә аларга гомумән дә ярамаган. Германия очрагында исә «уңышларны кичермәү»гә, уйдырма рәвешендә булсалар да, башка «гөнаһ»лар да өстәлеп, күренеш гипертрофик төсмер алган, миллионлаган яһүднең башын ашаган...

Җир йөзендә начар кешеләр бар, начар халыклар юк. Начар кешеләр без сөйләгән милләт турында әле бүген дә төрле уйдырмалар чыгарырга, конспирологиягә кереп китәргә, яһүдиләр тудырган ниндидер яшерен дөньяви хөкүмәт, аның әшәкелекләре хакында гәп куертырга яраталар. Олылар өчен язылган андый әкиятләргә ышанганчы, башка кавемнәргә, шул исәптән безгә – татарларга да ул халыктан үрнәк аласы, алардагы үҗәтлеккә, үзара дуслыкка, язмыш китергән сынауларга бирешмичә, үз-үзең булып калырга өйрәнәсе иде.

СИЗГЕР БУЛЫРГА КИРӘК

32 миллиард сум! Быелтыр Татарстанда төрле җинаятьләрдән зыян күрүчеләргә һәм дәүләткә әнә шулкадәр акчаны кире кайтарганнар. Моннан тыш, гаепле дип табылган затларның 6 миллиард сумлык милкенә арест салынган. «Бу – тармакта ирешкән иң яхшы нәтиҗә», – дип мактады Рөстәм Миңнеханов республика тикшерүчеләрен. Казанда Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча идарәсенең еллык коллегиясе узды.

Идарә җитәкчесе Валерий Липский сүзләренә караганда, былтыр теркәлгән җинаятьләр саны арткан. Ел дәвамында шундый 52 мең 189 очрак теркәлгән. Аның каравы авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр саны кимегән. Азмы-күпме, әлеге күрсәткеч 4 процентка төшкән. Узган ел 5 меңнән артык җинаятьне тикшергәннәр. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 13 процентка күбрәк.

Җинаять эшләрен тиз арада һәм сыйфатлы тикшерүнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын Президент та билгеләп үтте.

– Бу юнәлештә уңай якка үзгәреш бар. Җинаятьләр турындагы хәбәрләрне кабул итү, теркәү һәм тикшерү барышында, шулай ук җинаять эше кузгатканда законнарны үтәп, гражданнарны нигезсез рәвештә җинаять җаваплылыгына тартуга юл куймыйча, әлеге эшне алга таба да дәвам иттерергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент билгеләп үткәнчә, бүген ведомство алдында аеруча да җитди бурычлар тора. Махсус хәрби операция үткәрелү шартларында халык арасында иҗтимагый-социаль тотрыклылыкны саклау мөһим.

Валерий Липский китергән саннарга караганда, былтыр җинаятьчел төркемнәрнең 24 әгъзасы суд каршына баскан. Алар 41 җинаять кылган. Коррупциягә бәйле 650гә якын җинаять эше тикшерелгән. Акча урлауда 253 кеше гаепле дип табылган.

– Ришвәтчелек, торак-коммуналь система тармагында урлашу, дәүләт милке һәм бюджет чараларына бәйле җинаятьләрне тагын да нәтиҗәлерәк итеп тикшерергә кирәк, – дип киңәш итте республика башлыгы. – Юридик һәм урындагы затларның эшчәнлегендәге кимчелекләргә дә тиешле җавап булырга тиеш.

Президент хезмәт хакларын вакытында һәм минималь күрсәткечтән дә ким булмаган дәрәҗәдә түләү, «соры базар»га каршы көрәш кебек мәсьәләләргә дә игътибар юнәлтте.

«Көн кадагы»ннан төшмәгән тагын бер мөһим юнәлеш – террорчылык һәм экстремизмга каршы көрәш. Республика башлыгы фикеренчә, бүген террорчылык наркотиклар бизнесы, коралның законсыз әйләнеше, ялган акча басу һәм тарату кебек замана афәтләренә турыдан-туры бәйләнгән. «Бу күренешләрнең берсе дә калкып чыгарга тиеш түгел. Мондый җинаятьләргә каршы профилактика чаралары үткәрү, социаль тотрыклылыкка янаган куркынычларны вакытында ачыклау мөһим», – дип, киләчәккә эш билгеләде Президент.

Кулга-кул тотынып

«Бердәм Россия» партиясе проектларын нәтиҗәле, вакытында тормышка ашыру өчен партия әгъзаларының җирле хакимият органнары белән иңгә-иң торып эшләве кирәк. Партиянең Татарстандагы бүлеге төбәк Политсоветы президиумының Казанда узган утырышында катнашучылар шундый фикергә килде.

Чара партиянең төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин рәислегендә узды. Анда узган елда партия проектларын гамәлгә ашыру йомгаклары каралды һәм агымдагы елга планнар билгеләнде.

«Егермедән артыграк федераль проектны һәм республиканың кайбер проектларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотабыз. Икътисадны яхшыртуга, эшмәкәрлеккә ярдәм итү, мәдәни-тарихи яктан агарту, спортны үстерү һәм халык белән эшләүгә юнәлдерелгән бу изге проектларның очына чыгу өчен барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәргә кирәк. Ләкин партиянең кайбер җирле бүлекләре бу юнәлешләр буенча тиешенчә эшләми әле», – дип тәнкыйтьләп алды ул районнардагы коллегаларын.

«Башка партияләрнең кешеләргә, предприятиеләргә якын булган мондый проектлары юк. Бу эшне, партия активы һәм проектлар координаторлары мөмкинлекләреннән файдаланып, урыннардагы хакимиятләр белән берлектә башкарырга тиешбез. Һәрбер районга, һәрбер шәһәргә барып җитәргә кирәк», – дип, сүзенә йомгак ясады Фәрит Мөхәммәтшин.

ЗАРГА ҖАВАП ТАБЫЛА

Узган ел республиканың Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленә мөрәҗәгать итүчеләр саны арткан. Бер караганда, ил-көнгә бәйле сәбәпләрне исәпкә алсак, бу аңлашыла да. Әле бит хезмәт, мәгариф, сәламәтлек, гаилә, көнкүреш мәсьәләләренә бәйле зарлар да беркая да югалмый. Зарларга җавап табыламы? Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы эксперт советының киңәйтелгән утырышында узган елга хисап тоттылар.



tatarstan.ru

Кеше хокукларын бозу очраклары турында төрле чыганаклардан беләләр. 2022 елда республиканың Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына халыктан 5171 меңгә якын мөрәҗәгать кергән. Шул исәптән ГЛОНАСС системасыннан 1575 хәбәр алганнар. «Халык контроле» хезмәтендә урын алган 90 меңләп мөрәҗәгатьнең 6 меңнән артыгын вәкаләтле вәкил үз контроленә алган. Бер ел эчендә 78 тапкыр гражданнарны кабул итү уздырганнар. 623 кешегә ярдәм күрсәтелгән.

2022 ел мобилизация шаукымы белән дә истә калыр. Мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге дә шуңа бәйле, билгеле. Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская әйтүенчә, мобилизацияләнүчеләрдән, аларның туганнарыннан 4 меңнән артык мөрәҗәгать кабул иткәннәр. Юстиция министрлыгы белән берлектә мәгълүмати-консультатив төркем дә оештырганнар, хокукый ярдәм күрсәткәннәр.

Сәрия Сабурская сүзләренчә, халык сорауларының күп өлеше хезмәт урындагы мөнәсәбәтләр, гаилә, социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәгариф мәсьәләләренә дә кагыла. Җаваплы министрлыклар белән берлектә былтыр 8 «кайнар элемтә» уздырганнар. 409 шалтырату кабул иткәннәр. Бигрәк тә хатын-кызлардан сораулар күп килгән.

Коллегия утырышында Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева да катнашты. Хисапны тыңлагач, вице-премьер үз тәкъдимнәрен дә әйтте.

Иң элек бу мобилизацияләнүчеләр һәм аларның гаиләләренең мөрәҗәгатьләренә бәйле иде. «Мобилизацияләнгән гражданнарның хатыннарына, әниләренә һәм балаларына аерым игътибар күрсәтү кирәк. Бу барлык хакимият органнарына да кагыла. Ведомствоара хезмәттәшлек кирәк. Бу юнәлештә һәр сектор өчен барлык бурычлар да төгәл билгеле», – диде ул.

Моннан тыш җыелышып сөйләшү, «кайнар элемтә», «туры эфир», районнарга чыгу, урыннарда эшләү кебек чараларны арттырырга кирәк дип тә әйтте. Кайберләрен даими итү дә ярар иде. Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр белән нәтиҗәле эшләү бурычы да кала бирә. Монысын да системалы рәвештә башкару мөһим.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТЕРЛЕК САУЛЫГЫ – ИЛ БАЙЛЫГЫ

Нәтиҗә

Республикада мал-туарны йогышлы авырулардан сакларга, шәхси хуҗалыклардагы малларны исәпкә алырга, лейкозга каршы көрәшне тагын да көчәйтергә, кадрлар белән эшләүне тамырдан үзгәртергә. Быелгы планнар әнә шундый. Ветеринария тармагында планнар белән бергә проблемалар да җитәрлек. Барысы турында да Баш ветеринария идарәсе һәм Россельхознадзор хезмәтенең Татарстан буенча идарәсенең еллык коллегиясендә сөйләштеләр.

– Ветеринария хезмәте, гомумән, Россия аграрийлары өчен 2022 ел җиңелләрдән булмады, – дип башлады чыгышын Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов. – Санкцияләр аркасында даруларга кытлык башланды. Дөньяда аналоглары булмаган препаратлар бөтенләй юкка чыкты. Ләкин әлеге проблемалар федераль дәрәҗәдә тиз арада хәл ителде һәм ветеринария хезмәтендә зур проблемалар килеп чыкмады. Кыска вакыт эчендә чит ил препаратларын алмаштырырдай дарулар барлыкка килде.

Алмаз Хисаметдинов билгеләп узганча, терлекләрне исәпкә алу буенча да зур эшләр башкарылган. Бүгенгә республикадагы барлык мөгезле эре терлекнең 75 проценты «Хорриот» дип аталган бердәм системага кертелгән. Быелдан, ә төгәлрәге, 1 февральдән әлеге эшләр шәхси хуҗалыкларда да алып барылачак.

– Малларын исәпкә алдырганга халык акча түләмәячәк, моның өчен республика казнасыннан өлеш чыгарылды. Биркалар өчен акча районнарга мөгезле эре терлек һәм шәхси хуҗалыклар санына карап бүлеп бирелде инде, – дип аңлатты баш ветеринар.

Узган ел, кызганыч, дуңгызларда йогышлы һәм куркыныч авырулардан саналган африка чумасын гына читләтеп уза алмадык. Ел дәвамында аның 11 очрагы теркәлде, аларның бишесе кабан дуңгызларында булса, алтысы – шәхси хуҗалыкларда. Әлеге тиз тарала торган куркыныч авырудан Спас, Югары Ослан, Мамадыш, Чистай, Балык Бистәсе, Питрәч һәм Әлки районнары хуҗалыклары зыян күрде. Алга таба да ветеринарларның төп бурычы эре дуңгызчылык комплексларын йогышлы авырудан саклап калу иде. Шунлыктан дуңгыз асраучы шәхси хуҗалыклар саны мөмкин кадәр киметелде. Бүген шәхси хуҗалыклардагы дуңгызлар саны 2 мең 700 башка кадәр азайтылды.

– Йогышлы авыру таралганда, шәхси хуҗалыкларда 19 мең баш дуңгыз бар иде. Ул вакытта безнең башка чара булмады, – диде Алмаз Хисаметдинов. – Чөнки бүген әлеге хуҗалыкларда африка чумасы килеп чыгу һәм таралу куркынычы – иң зуры. Хуҗалар барлык ветеринария кагыйдәләрен үтәргә тиеш. Беренче чиратта, хайваннарны ябып кына тотарга, кыргый фауна белән бәйләнешкә кертмәскә һәм ризыкларны югары температурада эшкәртергә кирәк. Моннан тыш, республика африка чумасыннан тулысынча имин булсын дисәк, без ел саен кимендә 5 мең кабанны атарга тиеш. Бу – безнең бурычыбыз.

Биологик саклау дәрәҗәсе түбән булган дуңгызчылык хуҗалыклары да игътибар үзәгендә. Әлеге вакытта Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Түбән Кама һәм Сарман районнарында шундый алты хуҗалык бар. Аларда 2,5 мең баш дуңгыз асрала.

Мондый хуҗалыклар үзләренә йөкләнгән зур җаваплылыкны тоеп эшләргә тиеш, әлбәттә. Сүз уңаеннан, быел 1 марттан барлык таләпләргә дә җавап бирмәгән хуҗалыкларда йогышлы авырулар чыккан очракта юк ителгән терлекләр өчен компенсация түләнмәячәк.

Россиядә кош гриппы әле бер, әле икенче төбәктә чыгып торса да, узган ел

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан әлеге йогышлы авырудан имин булып саналды. Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы Илнур Галиев фикеренчә, ветеринария законнарын бозган хуҗалыкларның эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору да роль уйнаган.

Йогышлы авыруларга бәйле вазгыятькә авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров та басым ясады.

– 2022 ел нәтиҗәләреннән күренгәнчә, республика территориясенә йогышлы авырулар керү куркынычы иң актуаль һәм мөһим проблема булган. Баш ветеринария идарәсе һәм Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе әлеге мәсьәләдә җитәрлек эшләп бетерми, – дип шелтә белдерде ул.

Терлекләрдә лейкоз – белгечләрнең игътибар үзәгендә торган тагын бер җитди мәсьәлә. Бу уңайдан ветеринарларга Илнур Галиевтән дә тәнкыйть эләкте.

– Татарстан Россиядә иң эре сөт җитештерүчеләрнең берсе булып тора. Ләкин күп еллар дәвамында терлек лейкозы вирусына каршы нәтиҗәле көрәш алып барылмый. Хәзерге вакытта республика территориясендә мөгезле эре терлек лейкозы буенча 231 уңышсыз хуҗалык бар. Шуңа бәйле рәвештә бу юнәлештә эшне активлаштырырга һәм яхшыртырга кирәк, – диде ул.

Алмаз Хисаметдинов сүзләренчә, узган ел терлекләр арасында лейкоз авыруы 3,3 процентны тәшкил итә. 2021 ел белән чагыштырганда, күрсәткечләр 1,9 процентка кимегән. Ләкин кайбер районнарда бу проблемага зуррак игътибар бирергә кирәк.

Ахыры 3 нче биттә >

КАМАЛЫШ ҮЗГӘРТКӘН ТОРМЫШ

Тарих битләреннән

Дошманнар Ленинградны боҗрага камап алганда, Зинага 8 яшь була. Сугыш аларның гаиләсен аямый: кыз әтисен, сеңлесен югалта. Әмма бирешми. Сәламәтлегенә зыян килеп, бик зур авырлыклар кичерсә дә, аякка баса. Бүген Зинаида Бушуевага – 90 яшь. Ул безнең белән тагын бер тапкыр тормыш йомгагын сүтеп җыйды.

Соңгы көрәшү

– 1940 елда әтием Григорий Дыновны Финляндия чигенә хезмәт итәргә җибәрделәр. Хәтерлим әле: анда бер дә тыныч түгел иде. Аннан Юховец утравына күчерделәр. Без гаиләдә өч бала идек. Миңа – 8, энекәшем Юрага – 4, сеңлем Нинага – 2 яшь ярым. Бер ел тирәсе яшәгәнбездер, әтием «Тиз арада Выборг хәрби комиссариатына килеп җитәргә!» дигән телеграмма алды. Шулай итеп, ул китеп барды. Хәрби кеше булгач, без мондый күченүләргә, чакыруларга күнегеп беткән идек инде. Әмма ул чакта, соңгы күрешүебез дип, башка да кереп карамады. Мин аны гомерем буена эзләдем. Әмма архивлардан бернинди мәгълүмат та таба алмадым. Бары тик 1941 елда һәлак булганы гына билгеле. Гел күченеп йөргәнгә, истәлеккә хәтта бер фотосы да калмаган.

«Ни булса, шул булыр…»

Бомбалар шартлый башлагач, беренче айларда без күрше йортның подвалына кача идек. Ә анда юеш, салкын. Ахыр чиктә әнием: «Ни булса, шул булыр, башка интегә-интегә болай качып йөрмибез», – диде. Дошман самолетлары ут яудырганда да, өйдә генә утырдык. Ходай саклады: без яшәгән йортны бәла-каза урап үтте. Әмма ашар ризык, эчәр су запасы бик тиз кимеде. Өч бала белән эшсез калган әниемне йорт буенча җаваплы өлкән кеше үзенең ярдәмчесе итеп билгеләде. Аякта йөри алганнар, хәле булганнар янгын сүндерделәр, фатирлар буенча йөреп, исән кешеләрне барладылар, исәп-хисап алып бардылар. Үзе чыгып киткәндә, әнием мине өйдә өлкән итеп калдыра иде. Ипигә йөрү дә минем бурыч булды. Баштарак чиратлар бик озын иде, 2–3 сәгать торырга туры килде. Бераз вакыт үткәч, кеше саны кимеде, чөнки ачлыктан кырыла башладылар. Әнием муенга асарга янчык тегеп бирде. Мин анда икмәк карточкаларын сакларга тиеш булдым. «Кара аны, югалтсаң, без барыбыз да ачтан үләчәкбез», – дип кисәтте. Мин янчыкны гел күкрәгемә кысып карыйм, шулай итеп урынындамы-юкмы икәнлеген тикшерәм. Баштарак, икмәккә кушып, ярма да бирделәр, соңыннан ул бетте. Әнием азык эзләргә чыгып китә башлады. Көзен хуҗасыз калган бакчалардан кәбестә тамырлары алып кайтты, яфраклар җыйды. Ә кышка кергәч, су проблемасы калкып чыкты. Сулыклар катты, колонкалар эшләмәде. Безне бары тик яңа яуган кар гына коткарды. Пычрак иде ул, әмма кайнатып эчкәч, ярап торды.

Сентябрь аенда ачлык башланды. Азык-төлек саклана торган складлар янып беткән иде. Шуңа да нормаларны киметкәннән-киметә бардылар, бертуктаусыз һава тревогалары, шартлаулар булып торды… Бик куркыныч иде. Без дүрт бүлмәле коммуналь фатирның берсендә яшәдек. Буржуйкада яндырырлык әйбер калмагач, халык бергә укмашып яши башлады.

Беркөнне әнием озак кына кайтмады. Мин инде чиратта егылып үлгән кешеләрне күз алдына китереп, ниләр генә уйлап бетермәдем. Бервакыт хәлсезләнеп кайтып егылды. «Әнием, син нишләп озак кайтмый тордың?» – дип елый башладым. «Урам буйлап барам, – дип сөйли әни. – Көчкә-көчкә бер ат бара, аның артыннан кешеләр сөйрәлә. Барысы да, менә хәзер егылып үләр дә безгә ит булыр, дип өметләнәләр. Егып чалырга берсенең дә хәле юк. Мин дә озак кына ияреп бардым. Аннан хәлем бетте дә кайтып киттем».

Нинаның хәле бөтенләйгә начарланды. Әни безгә: «Барыгыз, балалар, Нина үләргә ята, саубуллашыгыз. Юньләп ашата алмадым. Гафу итсен инде», – диде. Без аның янына килдек. Энем бәләкәй бит әле, бернәрсә дә аңламый. Мин сеңлемнең күзләренә карадым. Ул әйтерсең лә сизенә, үзе дә безгә туп-туры карый, саубуллаша сыман. Ә күзләре шундый кечкенә, җыерчыкланып беткән… Тиздән ул безне ташлап китте. Аннан әнием урынга егылды. Шулай итеп, без үзебез дә караваттан бөтенләй тормый башладык.

Алып киттеләр

1942 елның апрелендә шәһәр буенча санитар пост бригадалары йөри башлады. Алар урамнарны иңләделәр, һәр йортка диярлек керделәр. Эпидемия, төрле йогышлы авырулар башланмасын өчен, көннәр җылынганчы, мәетләрне җыеп алырга кирәк иде. Күп кенә гаиләләр, артык икмәк карточкасы алыр өчен, мәетләрне яшереп тоттылар. Бер кеше дә исән калмаган фатирлар да җитәрлек булды. Санпостлар килгәндә, без ятып кына тора идек. Торып йөрергә хәл юк, шуңа күрә күршеләрнең дә ничек яшәгәнен белмәдек. Август ае якынлашкан иде инде. Көннәрдән беркөнне, носилкага салып, безне Ладога күле янына китерделәр. Хәлебез булмаганлыктан, шундук күчерергә базмадылар, күрәсең. Башта ашаттылар, хәл кергән кебек булды. Күл аша чыккач, товар поездына утырып, бик озак бардык. Кая барганыбызны да белмәдек. Вагонда халык бик күп кырылды. Аларны поезд туктаган саен төшерә бардылар.

Эвакуациядә

Безне Краснодар краеның Михайловская станицасында фатирларга керттеләр. Тик, немецлар килү куркынычы бар дип, бер айдан соң Казанга озаттылар. Килеп төшүгә, Бауман урамындагы 27 нче йортка урнаштырдылар. Заманында ул Бауман районы башкарма комитеты бинасы, аннан Горький исемендәге клуб булган. Зур залның идәнендә атналар буе йокладык. Кеше искиткеч күп иде. Соңрак безне Карл Маркс урамындагы 6 нчы йортка күчерделәр. Казан Кремленнән ерак түгел иде ул. 9 кв. метрлы бәләкәй генә бүлмә буш: карават та, чәй эчәргә чынаяк та юк. Әмма баштарак ул безгә кирәк тә булмады. Әнием белән икебезне дистрофиядән дәваларга хастаханәгә салдылар, ә Юраны приютка алдылар.

Азрак рәтләнгәч, әни авиация заводына эшкә йөри башлады. Миңа да 10 яшь тулды. Әмма укырлык түгел идем әле. Хәтерем дә зәгыйфьләнгән, уйлау сәләтем дә юк. Элеккеге халәтемә бик авырлык белән генә кайта алдым. Шуңа күрә мәктәпкә дә соңлап киттем. Уку авыр бирелде, булдыра алмаган чакларда, хурланып, үкси-үкси елый идем. Җиде сыйныфны тәмамлагач, җиңел сәнәгать техникумына кереп карадым, чөнки аны тәмамласаң, Ленинградка кайтып китү мөмкинлеге бар иде. Тик конкурс зур булганлыктан, үтә алмадым. Кичке мәктәптә белем алдым да бер елдан элемтә техникумына барып кердем.

Юллама белән мине Алтайга җибәрделәр. Шунда булачак ирем Григорий Бушуев белән таныштым. Гаилә кордык та яши башладык. Без, бәлки, шунда яшәп тә калган булыр идек. Әнидән хат килеп төште. 26 яшендә энем үлеп киткән. Аннан фатир алырга да чират тора идек. Уйлаштык та кайтырга булдык. Ул вакытта улыбыз Олег бар иде инде. Соңрак Валера туды. Мин, ясле булмау сәбәпле, баштарак эшкә урнаша алмадым. Эшләр көйләнгәч, Үзәк телеграфка урнаштым да пенсиягә чыкканчы эшләдем дә эшләдем.

Сәяхәтче әби

Шушы урында Зинаида Григорьевна, гомеренең бер өлешенә нокта куйгандай, тукталып калды. Әмма тирән бер сулыш алып, зиһенне җыю өчен генә иде бу. Лаеклы ялга киткәннән соң, аның эшләре тагын да арта. Нәкъ пенсиягә чыккан елны Зинаида Григорьевнаның оныгы туа. Ун ел гомерен аны тәрбияләүгә багышлый. Аннан оныгына шаяру катыш: «Син хәзер зур инде, әбиең, мөгаен, җырлый башлар», – ди. Әмма шаяртып әйтми ул бу сүзләрне. Чыннан да, сугыш һәм хезмәт ветераннары хорында 19 ел җырлап йөри. Шул елларда ире вафат булып, үзенең дә азрак сәламәтлеге какшап китә.

Хәзер ул кече улы Валера белән яши. Инде улы да пенсиягә чыккан. Шулай да эшсез тормый икән әле. Казандагы китапханәләр системасында электрон җиһазларны төзәтеп йөри. Ә Зинаида Григорьевна үзенә тагын да кәттәрәк шөгыль тапкан. Ул хәзер Россия буйлап сәяхәт итә. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Казанның Яңа Савин районында блокадада катнашучылар җәмгыятен җитәкли.

Зинаида Григорьевна Санкт-Петербург шәһәрендә дә еш була.

– Мин балачагым үткән урыннарга килеп эләккәч, бөтенләй аңлашылмый торган хисләр кичерәм. Уйларым да, зиһенем дә шул елларга әйләнеп кайта, – дип хатирәләргә бирелә ул. – Вокзалга килеп төшүгә, бөтен җирдә мәетләр ята, икмәк алырга чиратлар тезелгән кебек. Аптырагач, күзләремне йомам. Барыбер ярдәм итми. Күрәсең, мин генә түгел, башкалар да шулайдыр. Мондый ерткычлыкны кичереп тә, онытып та булмыйдыр ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Зинаида Бушуеваны «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләде.

ҖИҢҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Сез – Ватанга тугрылык үрнәге! Казан Кремлендә «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән Бөек Ватан сугышы ветераннары белән очрашканда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әнә шулай диде. Башкалада Ленинград блокадасын өзүнең 80 еллыгы һәм шәһәрне дошман блокадасыннан тулысынча азат итүнең 79 еллыгына багышланган тантаналы чара узды.

Президент ветераннарны әлеге истәлекле көн белән котлады.

– Бу – Бөек Ватан сугышы тарихының иң героик һәм фаҗигале битләре. Солдатларның тиңдәшсез батырлыгы. Ленинградта яшәүчеләрнең оешма һәм заводлардагы фидакарь хезмәте, герой-шәһәр халкының ныклыгы һәм каһарманлыгы 1943 елның кышында дошман блокадасын өзәргә ярдәм итте, ә бер елдан дошман оборонасы биреште, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент ассызыклаганча, Ленинградны азат итү өчен бик кыйммәт түләргә туры килде – блокадада яшәүче бер миллионнан артык кеше ачлык һәм кышкы суыклардан вафат булды. Ленинград янында фашистларны тар-мар итүгә Татарстан да зур өлеш керткән. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, әлеге сугышта республикада туган һәм яшәгән йөзләгән мең кеше катнашкан. Ни кызганыч, канкойгыч һөҗүмдә 45 меңнән артык якташыбызны югалттык. 17 кеше Советлар Союзы Герое һәм тагын 2 кеше Дан орденының тулы кавалерлары исеменә лаек булган. Тантаналы чарада яу кырында һәлак булучыларны бер минут тынлык белән искә алдылар.

– Моңарчы күрелмәгән масштабтагы эвакуация барышында совет Татариясе меңләгән ленинградлыны үз туганы кебек кабул итте. Дистәләгән завод һәм предприятие фронтны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итү өчен тырышып эшләде. Бу – чын мәгънәсендә хезмәт батырлыгы үрнәге, – диде республика башлыгы.

Камалышта калган Ленинградта яшәүчеләргә мөрәҗәгать итеп: «Сез – Ватаныбызга тугрылык үрнәге», – диде Рөстәм Миңнеханов. Бу сүзләр бүгенге шартларда аеруча да мөһим яңгырый. Президент әйтүенчә, махсус хәрби операция барышында Россия солдатларының батырлыгы дәвам итә. Президент ветераннарга рәхмәт әйтте һәм дәүләт бүләкләре тапшырды. Чара башланыр алдыннан, Казан Кремленә җыелучылар «Блокададагы герой-шәһәр Ленинград тарихында – Татарстан» дип аталган күргәзмә дә карады.

Йорт сатуның ние бар?

Фатир икән – иске йорттан да ярый, машина икән – урыны да булсын! Росреестрның Татарстан буенча идарәсе узган елга нәтиҗә ясады. Яңалык та әйттеләр. Алга таба милек сатканда һәм алганда риелторларның гомумән кирәге калмаска мөмкин.

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова әйтүенчә, быелтыр белгечләр 1 милионнан артык теркәү эше башкарган. Моннан тыш, халыкка 3 миллионга якын дәүләт хезмәте күрсәткәннәр. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу – өчтән бер өлешкә күбрәк. Шунысын да әйтик: барлык хезмәтләрнең яртысы диярлек электрон рәвештә күрсәтелгән.

Мисал эзләп ерак барасы да юк. Былтыр белгечләр 38 мең электрон ипотека рәсмиләштергән. Билгеле булганча, Татарстанда ипотеканы теркәү вакытын кыскартуга бәйле яңа проект 2021 елның сентябрендә эшли башлады. «Моңарчы бу эшкә бер атнага кадәр вакыт таләп ителсә, хәзер бер көн дә җитә», – ди Лилия Борһанова. Теркәүне кичектерүгә бәйле җитди сәбәпләр булмаса, әлбәттә. Проектның исеме дә җисеменә туры килә.

– Былтыр «Бер тәүлек эчендә ипотека» проекты кысасында, барлык электрон ипотекаларның 73 проценты бер көндә теркәлде, – диде җитәкче урынбасары.

Аның әйтүенчә, узган ел яңа торак базарында вазгыять үзгәргән.

– Төзелештә өлешләп катнашуга бәйле килешүләр саны – 18 меңгә, ягъни 11 процентка азрак теркәлде. Саннар кризиска кадәрге 2019 ел белән тигезләште, – диде Лилия Борһанова. – Аның каравы автомобильгә аерым урын сатып алучылар саны 18 процентка артты.

Ел йомгакларына багышланган очрашуда моны яңа торак комплексларының уңайлыклары күбрәк булуы белән аңлаттылар. Гомумән алганда, узган ел республикада 95 меңгә якын ипотека рәсмиләштергәннәр. Елның икенче чирегендә кредит алучылар саны кимүе дә күзәтелгән.

– Бу җәһәттән, дәүләт программалары торак базарын җанландырды. Былтыр Татарстанда яшәүче 6 мең 500дән артык кеше ташламалы ипотека рәсмиләштергән. Республика күләмендә 600ләп авыл ипотекасы теркәлгән. Исегезгә төшерәбез: ташламалы ипотека 2024 елның 1 июненә кадәр, ә авыл ипотекасы чиксез вакытка озайтылды, – диде җитәкче урынбасары.

Киләчәктә фатир сату-алу эше тагын да җиңеләергә, ә иң мөһиме, моңа бәйле чыгымнар кимергә мөмкин. Ник дигәндә, Росреестрның Татарстан буенча идарәсе яңа суперхезмәт гамәлгә кертергә җыена. «Минем торак» сервисы ярдәмендә үз торагыңны сатарга һәм шунда ук яңасын эзләргә мөмкин булачак, дип ышандыралар. Рәхәт бит, килешү төзү өчен өйдән чыгып та торасы юк. Сату-алу онлайн рәвештә генә башкарылачак. «Әлеге сервиста сатудагы күчемсез милек турындагы бөтен кирәкле мәгълүматны да табып булачак», – диде Лилия Борһанова. Мәсәлән, элеккеге хуҗаларның фатир өчен коммуналь түләүдә бурычлары бармы-юкмы икәнен ачыклау өчен, компьютер төймәсенә генә басарга кирәк булачак. Тик бераз сабыр итегез. «Минем торак» сервисы ел ахырында эшли башлаячак, дип көтелә. «Онлайн хезмәт булгач, риелторларның да кирәге калмыймы?» – дип тә сорадылар белгечтән. Җавап итеп: «Бу эш җиңеләячәк», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ДОГАЛЫ БОЗ

Спорт кына түгел бу

Хәзрәтләр, атакайлар да, кулларына кәшәкә тотып, бозга чыгачак. 1 февральдә Казанда хоккей буенча «Дуслык Кубогы» III бөтенроссия турниры башлана. Анда илнең алты төбәгеннән 250 спортчы катнашачак. Быелгы турнирда беренче тапкыр кызлар да алка сугачак.



«Татар-информ»

«Дуслык Кубогы» хоккей турниры Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Рус православие чиркәвенең Казан епархиясе тәкъдиме белән оештырыла. Әлеге чарага багышланган матбугат очрашуында Татарстан Хоккей федерациясенең вице-президенты Андрей Рябов әйтүенчә, башка бер җирдә дә моңа охшаш турнир юк. Турнирга КХЛ президенты Алексей Морозов, атаклы совет хоккейчылары Александр Якушев, Владимир Мышкин, Ирек Гыймаев кунак итеп чакырылган.

– Республикада төрле дин вәкилләре катнашында спорт ярышлары уздыру традициягә әйләнде. Спорт ул – берләшү, бөтен халыклар арасында дуслыкны һәм үзара аңлашуны ныгытуның мөһим чарасы. Быел турнир тагын да зуррак мәгънәгә ия, чөнки ул безнең ил өчен катлаулы чорда уза. Махсус хәрби операциядә катнашучы төрле дин һәм милләт вәкилләрен уртак максат берләштерә, – диде Андрей Рябов. Оештыручылар турнир барышында ватанпәрвәрлеккә, хәрби операция геройларын олылауга игътибар бирәчәк.

Татарстан Хоккей федерациясе вице-президенты әйтүенчә, быелгы ярышлар да узган елгы кебек чын хоккей фестиваленә әйләнәчәк. Турнирда яңа командалар да катнашачак. Башка еллардан аермалы буларак, кызлар да алка кертергә тырышачак.

1 февральдә Спорт сараенда узасы тәүге очрашуда башкаланың «Добрыня» һәм «Миллениум» командалары көч сынашачак. Журналистлар: «Киләсе елларда башка дин вәкилләрен дә чакырырга җыенмыйсызмы?» – дип тә сорады. Бу сорауга Андрей Рябов: «Бүген чикләүләр чорында вазгыять икенчерәк. Әмма без дуслык, татулык турында сүз барганда, теләсә кайсы тәкъдимгә ачык», – дип җавап бирде.

Узган елгы ярышларда бер командада мөселман, христианнар бергә уйнаган. Быел да шундый катнаш уен булырмы? Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфат хәзрәт Хәсәнов имамнар белән атакайлар кара-каршы түгел, берләшеп уйный торган уенның да булачагын әйтте.

Андрей Рябов әйтүенчә, ярышларда күңелне кузгата торган уен да бар. Физик мөмкинлеге чикле булган балалар катнашында «Хоккей һәркем өчен» хәйрия очрашуы узачак. Инвалид арбасына утырган балалар да Спорт сарае бозына кәшәкә тотып чыгачак.

Сәрия МИФТАХОВА

ТЕРЛЕК САУЛЫГЫ – ИЛ БАЙЛЫГЫ

< Ахыры. Башы 2 нче биттә

– Лениногорск, Яңа Чишмә һәм Чирмешән районнарында лейкоз белән авыручы терлекләр күп. Шулай ук Лаеш, Кама Тамагы, Спас районнарында да проблемалар бар, – диде идарә башлыгы.

Ә менә Саба, Әтнә, Балтач, Арча, Тукай, Кукмара, Алабуга, Сарман, Теләче районнарын үрнәк буларак тәкъдим иттеләр. Әлеге районнарда ел дәвамында авыру очраклары ачыкланмаган диярлек.

Терлекләр сәламәтлегенә килгәндә, узган ел бозауларны саклап калуга зур игътибар бирелсә, быел сыерларны бракка чыгару (авыру малларны иткә озату) мәсьәләсе төп юнәлеш булып торачак. Чөнки монда проблемалар шактый. Узган ел 94 мең сыер иткә озатылган, бу – гомуми терлекнең 36 проценты дигән сүз.

– Безнең республика өчен бу күрсәткеч күп дигәндә 20 процент булырга тиеш, – диде баш ветеринар. – Бракка чыгаруның сәбәпләре төрле. Маллар җилен шешү, гинекология авырулары, тын юллары, ашкайнату органнары, аяклары авырту, төрле җәрәхәтләр һәм сөт бирүе кимү аркасында иткә җибәрелә. Мондый күрсәткечләр белән без бервакытта да төп савым көтүен тутыра алмаячакбыз.

Әлеге мәсьәләгә Марат Җәббаров та басым ясады.

– Бу юнәлештә барлык районнар да тигез эшләми, – диде ул. – Ел дәвамында хуҗалыктагы сыерларның һәм таналарның яртысын бракка чыгарып барган хуҗалыклар бар. Моны булдырмый калу юлларын эзләү һәм чаралар күрү – быелгы төп бурычларның берсе.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Конституциясенә (2002 елның 19 апрелендәге 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9 – 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 3 – 4; 2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2010, № 3, № 11; 2012, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе составындагы демократик хокукый дәүләт. Татарстан Республикасы дәүләтчелеге, Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең бөтен тулылыгына Татарстан Республикасының ия булуында, аның үз территориясе, халкы, дәүләт хакимияте органнары системасы, үз Конституциясе һәм законнары, дәүләт телләре һәм дәүләт символлары булуында чагыла.»;

2) 3 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында хакимият аның күпмилләтле халкы тарафыннан турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.»;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә биргән вәкаләтләр чикләрендә халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра, тиешле килешүләр төзи, вәкилләкләр алмаша, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.»;

4) 9 статьяда:

а) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы судлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләренә алмаштырырга;

5) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья

Татарстан Республикасында идеологик күптөрлелек таныла. Бернинди идеология дә дәүләтнеке яисә мәҗбүри буларак билгеләнә алмый.»;

6) 15 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 21 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 24 статьяда:

а) беренче өлештә «хокукый системасында» сүзләрен «хокукый актлары системасында» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «Басылып чыкмаган законнар» сүзләрен «Басылып чыкмаган Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга, «норматив хокукый акт» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый акты» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасында халыкара хокукның Россия Федерациясе хокукый системасының состав өлеше булган гомумтанылган принциплары һәм нормалары кулланыла.»;

9) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья

Федераль законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә төзелергә мөмкин.»;

10) 29 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль, расачыл, милли билгеләр, тел яисә дин билгеләре буенча гражданнарның хокукларын чикләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела.»;

11) 33 статьяның икенче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

12) 50 статьяның өченче өлешендә «законда» сүзен «федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

13) 51 статьяда икенче җөмләне төшереп калдырырга;

14) 52 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«52 статья

1. Татарстан Республикасында һәркем, медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы. Медицина ярдәме дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә гражданнарга тиешле бюджет акчалары, иминият кертемнәре, башка акчалар исәбеннән түләүсез күрсәтелә.

2. Татарстан Республикасы һәркем өчен мөмкин булган һәм сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтүне, җәмәгать сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыруны, гражданнарның үз сәламәтлегенә җаваплы каравы культурасын булдыруны тәэмин итә.»;

15) 56 статьяның икенче өлешендә «мәктәпкәчә,» сүзеннән соң «башлангыч гомуми,» сүзләрен өстәргә, «башлангыч» сүзен «урта гомуми белем» сүзләренә алмаштырырга;

16) 67 статьяда «иң югары вәкиллекле, закон чыгару органы» сүзләрен «вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырырга;

17) 69 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булмаган, закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып сайланырга мөмкин.»;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.»;

в) түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм федераль закон нигезендә актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан сайлана.»;

18) 70 статьяда:

а) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.»;

б) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) алтынчы өлешнең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

19) 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«71 статья

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы һәм аның эшчәнлеге гарантияләре федераль закон һәм Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

20) 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«72 статья

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә яисә сайлана торган башка органнарның вазыйфаи затларына (Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына таләп белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Үзенә таләп җибәрелгән орган яисә вазыйфаи зат законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда телдән яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таләбе буенча язмача җавап бирергә тиеш.»;

21) 73 статьяда:

а) беренче өлештә «сайланганнан соң» сүзләрен «сайланган көннән алып» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«3. Яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшли башлаган көннән алып элеккеге чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре туктатыла.»;

22) 75 статьяда:

а) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 5 пунктта «, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты проектын карау» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) озак сроклы чорга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен һәм Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру тәртибен раслау;»;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларын һәм Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлеше турындагы хисапларны раслау;»;

д) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын оештыру тәртибен һәм аларның эшчәнлек тәртибен билгеләү;»;

е) 13 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 16 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

з) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) федераль закон һәм әлеге Конституция нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенә ышанычсызлык белдерү турында карар кабул итү;»;

и) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Премьер-министрын һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп кую турындагы тәкъдимнәрен килештерү;»;

к) 21 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

л) 22^1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

м) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне билгеләп кую;»;

н) түбәндәге эчтәлекле 23^1 пункт өстәргә:

«23^1) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне билгеләп кую;»;

о) түбәндәге эчтәлекле 24^1 пункт өстәргә:

«24^1) Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисен, Рәис урынбасарын һәм аудиторларын билгеләп кую;»;

п) 25 пунктта «сайлау округларын төзү» сүзләрен «сайлау округлары» сүзләренә алмаштырырга;

р) 28 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

с) 30 пунктта «, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен билгеләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

т) 31 пунктта «эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу» сүзләрен «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү» сүзләренә алмаштырырга;

23) 76 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салымнар (җыемнар) билгеләү, аларны гамәлгә кертү яисә гамәлдә булуларын туктату, салым ставкаларын (җыемнар ставкаларын), салымнар (җыемнар) түләү тәртибен һәм срогын үзгәртү, салым ташламаларын (җыемнар буенча ташламаларны) билгеләү (юкка чыгару) һәм (яисә) аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен билгеләү турындагы Татарстан Республикасы законнары проектлары, финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган чыгымнарны күздә тотучы башка Татарстан Республикасы законнары проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдиме буенча йә аның бәяләмәсе булганда карала. Әлеге бәяләмә закон проектын алган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла.»;

24) 77 статьяда:

а) икенче өлештә «Татарстан Республикасы законнары» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары» сүзләрен өстәргә, «әлеге Конституциядә» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга;

б) өченче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

25) 79 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«79 статья

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән Татарстан Республикасы законы 14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы законы кергән вакыттан алып 14 календарь көн эчендә аңа имза сала һәм аны халыкка җиткерә йә аны кире кага. Күрсәтелгән срок, әгәр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Россия Федерациясе Конституция Судына кабул ителгән Татарстан Республикасы законының конституциячеллеген тикшерү турында таләп җибәрелгән булса, туктатылып тора.

3. Татарстан Республикасы законын кире каккан очракта, Татарстан Республикасы Рәисе аны, ризасызлыклары белән бергә, кабат карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кире кайтара. Татарстан Республикасы законы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кире кагылган очракта, күрсәтелгән закон элек кабул ителгән редакциясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санының кимендә өчтән икесенең күпчелек тавышы белән хупланырга мөмкин.

4. Элек кабул ителгән редакциясендә хупланган Татарстан Республикасы законы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабат кире кагыла алмый, җиде календарь көн эчендә аңа имза салынырга һәм ул халыкка җиткерелергә тиеш.»;

26) 81 статьяда «Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлешен,» сүзләрен өстәргә;

27) 84 статьяда:

а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләре алдыннан «закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Татарстан Республикасы Конституциясендә, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган очракларда башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

в) 6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

28) 87 статьяда «дәүләт контролен» сүзләрен «тышкы дәүләт финанс контролен» сүзләренә алмаштырырга;

29) 88 статьяда:

а) беренче өлештә:

беренче абзацта «туктатылырга мөмкин» сүзләрен «туктатыла» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «үз-үзен таркату» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт Советын закон нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт Советын федераль закон һәм әлеге Конституция нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «үз-үзен таркату» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Үз-үзен таркату турында карар кабул иткәндә» сүзләрен «Әлеге статьяның беренче өлешендәге 1 пункты нигезендә үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул иткәндә,» сүзләренә, «үз-үзен таркату турындагы» сүзләрен «үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату хакындагы» сүзләренә алмаштырырга;

г) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре әлеге статьяның беренче өлешендәге 2 пункты нигезендә вакытыннан алда туктатылганда, Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

30) 2 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 БҮЛЕК. **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ**»;

31) 89 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«89 статья

1. Татарстан Республикасы Рәисе дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була.

2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының исеме – Татарстан Республикасы Рәисе.»;

32) 90 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«90 статья

Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауның, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре үтәлешенең гаранты булып тора.»;

33) 91 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«91 статья

1. Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булмаган, закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Рәисе булып сайланырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм федераль закон нигезендә актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп сайлана.

3. Татарстан Республикасы Рәисе биш елга сайлана.

4. Татарстан Республикасы Рәисен сайлауларны әзерләү һәм үткәрү тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.»;

34) 92 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«92 статья

1. Татарстан Республикасы Рәисе федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Рәисе, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен куллана.»;

35) 93 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Рәисе, үз вазыйфасына керешкәндә, Татарстан Республикасы халкына һәм Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә тугрылыклы булырга түбәндәге рәвештә ант итә: «Татарстан Республикасының күпмилләтле халкына тугрылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәргә, Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Рәисенең миңа йөкләнгән югары вазыйфаларын намус белән үтәргә тантаналы төстә ант итәм».»;

г) дүртенче өлештә «, Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Рәисе Штандарты (флагы) була.»;

36) 94 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«94 статья

1. Татарстан Республикасы Рәисе:

1) Татарстан Республикасында гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасы дәүләтчелеген яклауны, билгеләнгән чикләрдә аның территориясен саклауны, Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать иминлеген, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итә;

2) Татарстан Республикасында башкарма хакимияткә җитәкчелек итә һәм аның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлеген тәэмин итә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

3) Татарстан Республикасының эчке сәясәтен һәм тышкы эшчәнлек юнәлешләрен билгели;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына карау һәм раслау өчен ел саен Татарстан Республикасы бюджеты турындагы һәм аның үтәлеше хакындагы законнарның проектларын тәкъдим итә;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына озак сроклы чорга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен тәкъдим итә;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турындагы еллык юллама белән мөрәҗәгать итә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республика тормышының мөһим мәсьәләләре хакында мәгълүмат бирә;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре турында еллык хисапларны, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны тәкъдим итә;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын төзи, аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының отставкасы турында карар кабул итә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Премьер-министрын, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп куя, Татарстан Республикасы министрларын, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләрен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен билгеләп куя. Татарстан Республикасы Премьер-министрын, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын, Татарстан Республикасы министрларын, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләрен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен вазыйфаларыннан азат итә;

9) Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасын һәм структурасын билгели;

10) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

11) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

12) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны тәкъдим итә;

13) федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне вазыйфасына билгеләп куя;

14) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын билгеләп куя;

15) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе Дәүләт Советы, башка органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар белән мөнәсәбәтләрдә һәм Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртә; Татарстан Республикасы исеменнән шартнамәләргә һәм килешүләргә имза сала; Россия Федерациясендә, аның субъектларында, чит дәүләтләр субъектларында һәм административ-территориаль берәмлекләрендә, шулай ук чит дәүләтләрдә һәм халыкара оешмаларда Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп куя һәм чакыртып ала;

16) Татарстан Республикасы законнарына имза сала һәм аларны халыкка җиткерә йә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән законнарны кире кага;

17) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасы Рәисе указларына каршы килгән очракта, аларны юкка чыгара;

18) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкли;

19) Татарстан Республикасы премияләрен гамәлгә куя һәм аларны тапшыра;

20) Татарстан Республикасында ярлыкау мәсьәләләрен карау комиссиясен төзи һәм ярлыкау акты куллануның максатка ярашлылыгы турында Россия Федерациясе Президентына тәкъдим кертә;

21) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын чакыруны таләп итәргә, шулай ук яңа сайланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советын беренче утырышка шуның өчен билгеләнгән срок эчендә чакырырга хокуклы;

22) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы эшендә киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хокуклы;

23) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар белән хезмәттәшлеген оештыра;

24) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, Россия Федерациясе карамагындагы эшләр һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы эшләр буенча кабул ителгән федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килүче Татарстан Республикасы Конституциясе һәм (яисә) Татарстан Республикасы законы, башка норматив хокукый акт кабул ителгән очракта, әгәр, мондый каршылыклар тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы суд карары үз көченә кергән көннән алып алты ай эчендә аларны бетермәгән булса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итә;

25) федераль законнар һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен алар тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен муниципаль берәмлек башлыгына, җирле администрация башлыгына кисәтү ясарга, шелтә белдерергә хокуклы;

26) муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы әлеге статьяның беренче өлешендәге 25 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе муниципаль берәмлек башлыгына, җирле администрация башлыгына кисәтү ясаган, шелтә белдергән көннән алып бер ай эчендә үз вәкаләтләре чикләрендә аңа кисәтү ясау, шелтә белдерү өчен нигез булган сәбәпләрне бетерү чараларын күрмәсә, муниципаль берәмлек башлыгын, җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан читләштерергә хокуклы;

27) федераль законда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү инициативасы белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шул исәптән җирле үзидарә органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренә даими рәвештә ирешмәгән очракта да;

28) Татарстан Республикасы Рәисе Штандарты (флагы) турындагы нигезләмәне раслый;

29) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Рәисе үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен үз Администрациясен төзи, аның Җитәкчесен билгеләп куя.»;

37) 95 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе» сүзләрен «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә, федераль конституциячел законнар» сүзләренә алмаштырырга;

38) 96 статьяда «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

39) 97 статьяда:

а) беренче өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» сүзләре алдыннан «Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга яисә» сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре Россия Федерациясе Президентының карары яисә Россия Федерациясе Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Рәисенә түбәндәге очракта ышанычсызлык белдерергә хокуклы:

ул Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килүче актлар чыгарганда, әгәр, мондый каршылыклар тиешле суд тарафыннан билгеләнгән булып, Татарстан Республикасы Рәисе суд карары үз көченә кергән көннән алып бер ай эчендә әлеге каршылыкларны бетермәсә;

Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясе Президенты указларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы законнарын башкача тупас бозу тиешле суд тарафыннан билгеләнгәндә, әгәр бу гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен массакүләм рәвештә бозуларга китерсә;

Татарстан Республикасы Рәисе үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгәндә.»;

г) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

д) бишенче өлештә «Президентка» сүзен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

е) алтынчы өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

40) 98 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«98 статья

1. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә аны вакытлыча вазыйфасыннан читләштергән очракларда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы турында указ чыкканчы, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе үз вәкаләтләрен сәламәтлеге хәленә яисә үз вәкаләтләрен башкаруга вакытлыча комачаулаган башка хәлләргә бәйле рәвештә башкара алмаган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча Татарстан Республикасы Премьер-министры башкара.

2. Федераль законда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләп куела.

3. Әлеге статьяның беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советын таркатырга, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә, шулай ук үз инициативасы белән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләрен вазыйфаларыннан азат итәргә хокуксыз.»;

41) 99 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте – иң югары даими эшләүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы.»;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

42) 100 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«100 статья

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә, һәм аны Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы министрлары, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары рәисләре тәшкил итә. Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләрен кертә ала.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәисе була һәм аның эшен оештыра.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела.»;

43) 101 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче өлештә «Премьер-министр урынбасарларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларына» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

44) 102 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«102 статья

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) финанс, фән, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, социаль тәэминат, юл хәрәкәте иминлеге һәм экология өлкәләрендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша;

2) кешенең һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру, тәэмин итү һәм яклау, милекне һәм җәмәгать тәртибен саклау, террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы тору, җинаятьчелеккә каршы көрәш чараларын күрә;

3) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

4) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү, милли азчылыкларның хокукларын яклау, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү, милләтара (этникара) низагларны профилактикалау һәм милләтара, конфессияара татулыкны тәэмин итү чараларын күрә;

5) сәламәтлек саклау мәсьәләләрен координацияләү, шул исәптән һәркем өчен мөмкин булган һәм сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтү, җәмәгать сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру, гражданнарның үз сәламәтлегенә җаваплы караву культурасын булдыру, чараларын күрә;

6) халыкны социаль яклауның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү чараларын, социаль тәэминатны да кертеп, гражданнарга адреслы социаль ярдәм чараларын күрә;

7) гаиләне, ана булуны, ата булуны һәм балачакны яклауны, ир-атның һәм хатын-кызның берлеге буларак никах институтын яклауны тәэмин итү, балаларны гаиләдә лаеклы итеп тәрбияләү, шулай ук балигъ булган балаларның үз ата-аналарын кайгырту бурычын башкару өчен шартлар тудыру чараларын күрә;

8) Татарстан Республикасы бюджеты проектын әзерли;

9) Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итә һәм аның үтәлеше турында хисапны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре хакында еллык хисапны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык докладны аларны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү өчен әзерли;

10) Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы милкенә идарә итә һәм аның белән эш итә, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы идарәсенә тапшырылган федераль милеккә идарә итә;

11) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы стратегик планлаштыру документларын әзерләү һәм төзәтү тәртибен билгели һәм мондый документларны раслый (хуплый);

12) җирле үзидарә органы, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм бүтән норматив хокукый актларына каршы килә торган хокукый актлар чыгарылган очракта, җирле үзидарә органына, җирле үзидарәнең вазыйфаи затына аларны законнарга туры китерүне тәкъдим итә, шулай ук судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы;

13) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары турында нигезләмәләр раслый;

14) Татарстан Республикасы Конституциясендә, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләрдә, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына федераль башкарма хакимият органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыруны күздә тотучы Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

45) 103 статьяда «Татарстан Республикасы Конституциясенең,» сүзләреннән соң «федераль конституциячел законнарның,» сүзләрен өстәргә;

46) 105 статьяның икенче өлешендә «һәм дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

47) 4 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 БҮЛЕК. **СУД ХАКИМИЯТЕ. ПРОКУРАТУРА. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СОВЕТЫ**»;

48) 107 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«107 статья

Татарстан Республикасында суд хакимияте федераль судлар һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

49) 108 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

50) 109 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

51) 110 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

52) 112 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

53) 114 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«114 статья

Прокуратура органнары вәкаләтләре, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе федераль закон белән билгеләнә.»;

54) түбәндәге эчтәлекле 114^1 статья өстәргә:

«114^1 статья

Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция советы төзелергә мөмкин.»;

55) 115 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«115 статья

Гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында, шул исәптән хөкем итүне гамәлгә ашырганда, аларга юридик ярдәм адвокатлар һәм башка затлар тарафыннан закон нигезендә күрсәтелә.»;

56) 116 статьяда:

а) беренче өлештә «, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) икенче өлештә «, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре үз рәсми символларын билгеләргә хокуклы.»;

57) 117 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«117 статья

1. Җирле үзидарә муниципаль берәмлекләрдә гамәлгә ашырыла, аларның төрләре федераль закон белән билгеләнә. Муниципаль берәмлекләр территорияләре тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары структурасы федераль законда билгеләнгән Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары нигезендә халык тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

3. Җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган территорияләрнең чикләрен үзгәртү тиешле территорияләр халкының фикерен исәпкә алып рөхсәт ителә һәм Татарстан Республикасы законы белән гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт хакимияте органнары федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда җирле үзидарә органнарын төзүдә, җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын вазыйфаларына билгеләп куюда һәм вазыйфаларыннан азат итүдә катнашырга мөмкин.»;

58) 118 статьяда:

а) беренче өлештә «билгелиләр» сүзен «кертәләр» сүзенә алмаштырырга, «җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыралар, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «, шулай ук федераль закон нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә медицина ярдәменнән файдалана алуны тәэмин итәләр» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керәләр һәм тиешле территориядә яшәүче халыкның мәнфәгатьләрендә мәсьәләләрне аеруча нәтиҗәле хәл итү өчен хезмәттәшлекне гамәлгә ашыралар.»;

59) 119 статьяда «дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү хокукы,» сүзләрен «җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлектә гавами функцияләрне башкару нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү хокукы, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

60) 120 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«120 статья

Муниципаль хокукый актлар Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларына каршы килмәскә тиеш.»;

61) 121 статьяның беренче өлешендә «суверенитетын» сүзен «дәүләтчелеген» сүзенә алмаштырырга, «Татарстан халкының» сүзләрен «Татарстанның күпмилләтле халкы» сүзләренә алмаштырырга;

62) VII кисәккә түбәндәге эчтәлекле 122^1 статья өстәргә:

«122^1 статья

Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары төркеме, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан кертелергә мөмкин.»;

63) 125 статьяда:

а) беренче өлештә «ундүрт календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә, «ундүрт календарь көн эчендә» сүзләрен «14 календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

64) 126 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесенең күпчелек тавышы белән элек кабул ителгән редакциядә хупланган Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кабат кире кагыла алмый, җиде календарь көн эчендә аңа имза салынырга һәм ул халыкка җиткерелергә тиеш.».

2 статья

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешен (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

3 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергәнче кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларында, аларга тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының «Татарстан Республикасы Президенты» исеме һәм «Татарстан Республикасы Рәисе» исеме бер үк мәгънәгә ия була.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 26 гыйнвар. № 1-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЛАРЫ

20 гыйнвар, 2023 ел Казан ш. № 8/45

2022 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 10 гыйнвар, 2023 ел, № 108 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 10 гыйнвар, 2023 ел, № 108 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. Бу карарны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

4. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары А.А. Нефедовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

20 гыйнвар, 2023 ел Казан ш. № 8/46

2022 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматларны раслау хакында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы И.Р. Вәлиуллин мәгълүматын тыңлап, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалында һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VIII бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматларны (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу карарны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

3. Бу карарны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
20 гыйнвар, 2023 ел,
№ 8/46 карарына кушымта

2022 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматлар

Ел ае	Телеканал, радиоканал	Сәяси партияләр атамасы	
		«БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясе	«РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ» сәяси партиясе
		Эфир вакыты күләме (сәгать:минут:секунд)	
гыйнвар 2022 ел	телеканал	0:42:57	0:42:54
	радиоканал	0:37:19	0:37:16
февраль 2022 ел	телеканал	0:39:57	0:39:55
	радиоканал	0:34:24	0:34:20
март 2022 ел	телеканал	0:42:07	0:42:02
	радиоканал	0:37:31	0:37:29
апрель 2022 ел	телеканал	0:44:07	0:44:04
	радиоканал	0:39:18	0:39:13
май 2022 ел	телеканал	0:44:18	0:44:14
	радиоканал	0:38:23	0:38:24
июнь 2022 ел	телеканал	0:42:11	0:42:06
	радиоканал	0:37:36	0:37:34
июль 2022 ел	телеканал	0:42:57	0:42:54
	радиоканал	0:37:19	0:37:16
август 2022 ел	телеканал	0:45:08	0:45:04
	радиоканал	0:39:24	0:39:19
сентябрь 2022 ел	телеканал	0:42:37	0:42:35
	радиоканал	0:40:55	0:40:54
октябрь 2022 ел	телеканал	0:44:18	0:44:16
	радиоканал	0:41:21	0:41:18
ноябрь 2022 ел	телеканал	0:45:06	0:45:04
	радиоканал	0:41:59	0:41:58
декабрь 2022 ел	телеканал	0:46:03	0:45:59
	радиоканал	0:42:59	0:42:57
Бер ел эчендә барлыгы	**телеканал**	**8:41:46**	**8:41:07**
	радиоканал	**7:48:28**	**7:47:58**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырыгынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.

2. «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 381-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 376-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 2 һәм 45 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 377-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

5. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 379-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

6. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 378-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 380-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Татарстан – Яңа гасыр» депутат төркеменең 2019 елның сентябреннән 2023 елның гыйнварына кадәрге эше турында хисап.

9. Татарстан Республикасы Иннополис шәһәрендә пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә экспериментал хокукый режим билгеләү мөмкинлеге турында.

10. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 266491-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Сириус» федераль территориясе гавами хакимият органнары вәкаләтләре составын һәм үзенчәлекләрен төгәлләштерү өлешендә).

11. «Россия Федерациясендә архив эше турында» Федераль законның 24 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 260061-8 номерлы федераль закон проекты турында (архив документларын һәм аларны белешү-эзләү чараларын ерактан торып куллануның дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм аннан файдалану өлешендә).

12. «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законга һәм «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 265452-8 номерлы федераль закон проекты турында (лицензияләнә торган эшчәнлек төрләрен киңәйтү өлешендә).

13. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 261044-8 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт реестрлары белешмәләрендәге каршылыкларны бетерү өлешендә).

14. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 60 статьясына үзгәреш кертү турында» 260064-8 номерлы федераль закон проекты хакында (төзелеш өлкәсендәге үз-үзен җайга салучы оешмаларның биналар, корылмалар милекчеләренә бу оешмалар әгъзалары тарафыннан сыйфатсыз башкарылган эшләр аркасында зыян китергән өчен җаваплылыгын җайга салуны оптимальләштерү мәсьәләсе буенча).

15. «Су белән тәэмин итү һәм суны җибәрү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 254884-8 номерлы федераль закон проекты турында (коммуналь хезмәтләр күрсәтүне камилләштерү өлешендә).

16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 һәм 4.8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 253855-8 номерлы федераль закон проекты турында (сроклар исәпләү тәртибен төгәлләштерү хакында).

17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.6^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 260063-8 номерлы федераль закон проекты турында (контроль (күзәтчелек) орган тарафыннан хокук бозуларны бетерү хакында күрсәтмә бирү бурычын үтәмәгән өчен җаваплылык билгеләү турында).

18. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 265468-8 номерлы федераль закон проекты турында (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне хокукка каршы тараткан өчен җаваплылык билгеләү хакында).

19. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 97 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 261070-8 номерлы федераль закон проекты турында («Белем сыйфатын бәяләүнең федераль мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасын булдыру өлешендә).

20. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 26 гыйнвары
№ 1801-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп өч елга түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:

4 нче суд участогына – Гайфетдинова Розалия Зәки кызын.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 26 гыйнвары
№ 1802-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада архив эшен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең белешмәләр-эзләү системалары бүлеге башлыгы **Глинских** Елена Геннадьевна; законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе кадрлар бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция полковнигы **Жуков** Антон Фәрит улы, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Идарәсе полиция башлыгы, полиция полковнигы **Чекмарев** Михаил Викторович; республикада экологик куркынычсызлыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе дәүләт экология экспертизасы һәм рөхсәт кәгазьләре бирү эшчәнлеге төбәкара бүлеге башлыгы урынбасары **Осипов** Алексей Борисович; күпьеллык намуслы хезмәтләре, республика халкын пенсия белән тәэмин итү системасын камилләштерүгә өлеш кертүләре өчен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге клиентлар белән эшләү хезмәтләре эшен оештыру идарәсе башлыгы **Петрушина** Анна Юрьевна, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге Чистай районындагы клиентлар белән эшләү хезмәте (бүлек хокукында) җитәкчесе **Сергеева** Надежда Александровна; гуманитар проектларны тормышка ашыруга зур шәхси өлеш кертүе һәм актив гражданлык позициясе өчен «В.Штольц мәктәп-студиясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Петряев** Владимир Генадиевич; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе ресурслар белән тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары секторы мөдире **Шәрәфетдинова** Ландыш Әнәс кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Тимерхан Бизнес» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кейтеринг менеджеры **Агарков** Максим Викторович, хезмәт ветераны **Денисов** Николай Дмитриевич, «Тимерхан Бизнес» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2 нче корпусы администраторы **Исмәгыйлев** Илшат Әюп улы, **Корсаков** Владимир Григорьевич, «Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесенең юл участогы мастеры **Морзабаев** Марсель Ишморза улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«БӨРЕЛЕ» ябык акционер җәмгыяте генераль директорының җәнлекләр үрчетү буенча урынбасары – баш ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Большаков** Анатолий Дмитриевичка, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе ветеринария иминлеген тәэмин итү, ветеринария-санитария экспертизасы һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Сәлахов** Айрат Рөстәм улына, «Мамадыш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Тәкәнеш ветеринария участогы ветеринария табибы **Хаҗиев** Маннур Фазыл улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«НУР» АГРОФИРМАСЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сыер савучысы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Бәдретдинова** Резеда Илзар кызына, «Элита» нәселле терлек үрчетү баш предприятиесе» акционер җәмгыятенең нәселле үгезләр карау буенча операторы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Вафина** Рузалия Данил кызына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең филиалы «Ялтель» кошчылык фабрикасы операторы-кош караучысы **Зиганшина** Венера Мәгъсүм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Элита» нәселле терлек үрчетү баш предприятиесе» акционер җәмгыятенең баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Кәбиров** Фәнил Васил улына, «АГРОКӨЧ» акционер җәмгыяте баш зоотехнигы – терлекчелек бүлеге башлыгы урынбасары **Ситдыйков** Ленар Өлфәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе хезмәткәрләре: Чистай территориаль органының контроль-инспекция бүлеге әйдәүче белгече-эксперты **Бабаева** Надежда Александровнага, алкоголь продукциясе әйләнешенә контроль һәм кулланучылар базары торышына анализ бүлеге әйдәүче белгече **Бирюкова** Анна Леонидовнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Минем сагыну сезнең өегезгә...»

Минем сагыну сезнең өегезгә
Синнән алда кайтып җитәр дә,
Син керүгә, назлы песиең булып,
Күтәрттерер үзен җилкәңә.

Син назларсың аны «йомшагым» дип,
Кочагыңа алып сөярсең.
Беркемгә дә әйтмәс серләреңне
Аңа гына ышанып сөйләрсең.

Ә бер читтә Сөю карап торыр,
Бу күренешкә чиксез куанып.
Сагынуым калыр синең белән,
Йомшак чәчләреңә уралып.

Син сизмәссең берни, ә шулай да,
Чәчләреңә куйсаң кагылып.
Бер яктылык төшәр йөзләреңә,
Тәрәзәдән кергән Ай булып.

Фәнис ЯРУЛЛИН

ЙӨРЕГЕЗ!

Йомышың төшеп, хастаханә тирәсенә барганда, каршыңа уртача буйлы, бер иңенә биштәрен аскан, икенче кулын җай гына селтәп, уйчан йөзле берәү килүен күрсәң, шул үзе булыр – йөрәк-кан тамырлары авырулары буенча күп методик әсбаплар, белешмәләр, фәнни хезмәтләр авторы Нур Сибгатуллин. Әлмәттә аның турында «йөрәк Алласы» дип юкка гына әйтмиләрдер. Сөйләшә, аралаша башлагач, аз сүзле икәнен дә өстәп куйыйк әле. Бүген киң таралган атеросклероз, йөрәк-кан тамырлары авырулары, ягъни хезмәте турында туктамый сөйләсә дә, үзе турында саран гына әйтеп куя ул. Бу юлы ничектер уртак тел таптык әле.

– Әтием – тарих фәне, әнием башлангыч сыйныфлар укытучылары иде. Алты яшьтән укырга керергә теләгән идем, әти җибәрмәде. Мин, ачудан, әтием алып кайткан өр-яңа итекне кадак белән идән уртасына кагып куйдым. Минем шундый укыйсым килә иде! Икенче елда без, биш малай, кердек. Бик дус һәм тату булып, мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамладык. Ә теге елны укырга кергән малайлар бик шук булдылар. Әти сизенгәндер инде, шуңа каршы төшкәндер, – дип искә алды ул балачагын.

Беренче тапкыр табиблар белән ничек очрашуы турында да сөйләп алды.

– Миңа дүрт яшьләр тирәсе иде, катлаулы операция кичердем. Район үзәгеннән 30 чакрым ераклыктагы хастаханәгә алып барды әти. Операция вакытында янымдагы апаларның сөйләшүен тоям, аз гына аңыма киләм дә, алар миңа нидер иснәтәләр. Эфир булган ул. Бик көчле агулы наркоз. Хәзер кулланылмый инде.

Шул операциядән соң бик каты авырый ул. Йөри алмый башлый. Күбрәк хәрәкәтләнергә, спорт белән шөгыльләнергә тырыша. Мәктәптә дә зур омтылыш белән укый.

Очучы булырга теләгән Нур Сибгатуллин. Сугышта катнашкан очучылар турында бөтен китапларны укып чыга ул. Комиссия үткән вакытта күзе белән проблема булу сәбәпле, хыялы тормышка ашмый кала. Табиб булу теләге дә көчле була. Авылдашлары, профессор, Мәскәүдә аспирантура тәмамлаган кардиохирург, 1958–1960 нчы елларда ук йөрәккә операция ясаган Наил абыйсы турында еш сөйли аңа әтисе. Бервакыт шулай газеталар укып утырганда, Мәскәү университетына укырга керергә теләүчеләр өчен читтән торып әзерлек курслары ачылу турындагы белдерүне күреп ала. Мәктәп белән бергә шул әзерлек курсларын да уңышлы тәмамлый. Башкорт Дәүләт медицина институтына укый. Спорт белән шөгыльләнә. Ярышларда уку йорты данын яклый.

Студент еллары да мәңгелеккә хәтергә уелып кала.

– И сагындыра, и кайтасы килә иде инде. 28 сум стипендия бирәләр. 24 сумына шунда ук талон алып куям. Җитми, әниләр дә ярдәм итә алмыйлар. Урам себерүче булып эшкә кердем. Утыз сум хезмәт хакы түлиләр. Әле дә искә төшә ул тыкрыклар.

Дүртенче курста медбрат булып эшкә урнаша. Бишенче, алтынчы курсларда ашыгыч ярдәм системасында эшли. Хезмәт тәҗрибәсе аның өчен файдалы тормыш мәктәбе була. Авыруны күрүгә, диагноз да куя ала башлый.

– Иң күп таралган авырулар исәбендә беренче урында йөрәк-кан тамырлары авыруы тора, – ди ул. – Бүген йөрәк авыруларын диагностикалау киң таралган. Инструменталь тикшерүләр, ультратавыш, компьютер томографияләре, коронарография үткәреп, һәр чирнең башлангыч чорын белеп була. Йөрәккә зонд белән кереп тикшерү ысулы да киң таралды. Аның ярдәмендә кан юлларындагы төерчекләрне ачыкларга мөмкин. Аларның кечкенәме, зурмы һәм ни дәрәҗәдә зарарлы икәнен белеп дәвалау ысуллары бар. Кечкенәләреннән дарулар белән котылып була. Инде дарулар белән генә дәвалап булмас кебекләренә операция ясыйбыз. Йөрәкнең клапаннарына килгәндә, мәсәлән, йөрәк пәрдәләре бер-берсенә ябыша. Операция юлы белән шушы пәрдәләрне эшләтеп җибәрү мөмкин. Ясалма клапаннар куеп яисә үзенең клапаннарына реконструкция ясау алымнары киң таралган. Инфаркт, инсульт булганчы күреп алганда, ярдәм итү дә җиңелрәк.

Интернетны, хәзер бигрәк тә кесә телефоннарын бераз читкә куеп, ашауны, диетаны катгый тоткан кеше бу авырудан саклана ала, әлбәттә. Җәяү йөрү бик файдалы. Операция ясаттым да, шуның белән бетте дип кенә уйларга һич ярамый. Авыру янә азып китмәсен өчен, сәламәт яшәү рәвеше, диета, хәрәкәтләнү кирәк. Спорт белән даими шөгыльләнү үземнең мөмкинлекләремне бәяләргә дә өйрәтте. Арыганыңны вакытында сизеп алу бик мөһим.

Нур Гасыйм улы Сибгатуллин 1953 елның 29 ноябрендә Башкортстанның Дәүләкән районы Чуенчы авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1985–1990 елларда хирургия буенча ординатура тәмамлый, аспирантурада әзерлек үтә. 2008 елдан Әлмәт шәһәре «Татнефть» һәм шәһәр медицина-санитария частенда йөрәк хирургиясе бүлеге мөдире. 335 фәнни хезмәт һәм 43 уйлап табу авторы. Россия йөрәк-кан тамырлары хирурглары җәмгыяте әгъзасы. «Ак чәчәкләр» республика конкурсының «Ел табибы» номинациясендә җиңүче. Татар һәм рус телләрендә шигырьләр дә яза. Беренче шигырьләре белән «Туган яктан илһам алып» җыентыгында танышырга мөмкин. 2020 елда «Каләм гаме» исемле китабы чыкты.

Кыска гына, әмма адәм баласына бик аңлаешлы итеп ирештерә торган киңәше дә бар Нур Сибгатуллинның: «Йөрегез! Йөрү, хәрәкәт итү – үзе сәламәтлек ул!»

Минзифа ӘХМӘТШИНА.
Әлмәт

Дөрес түгел бит инде

Татарстанда ярты ел эчендә 9213 пар кавышкан. Шуның 6 меңгә якыны таралган. Күп бу, бик күп.

Кавышкан парлар ансат кына аерылмасыннар өчен, мин гариза язганда ару гына салым түләттерергә тәкъдим итәм. Иң мөһиме, суммасы зур булсын. Өч ай уйланырга вакыт бирергә кирәк. Анда да татуланмыйлар икән, пошлина хакында сүз кузгату мәслихәт. Хөкүмәт файдасына саллы гына акча түләсеннәр. Шуннан соң нәтиҗәсе күренәчәк. Бу әйберләр дә куркытмый икән – аерылсыннар. Миллион сум түләсеннәр. Димәк, чыннан да, барып чыкмый дигән сүз бу.

Безнең бабайлар, хәллерәкләре инде, әлбәттә, кызларын зур бирнә белән кияүгә биргәннәр. Бер өлешен биреп бетермәгәннәр. Бабай кеше кияүгә болай аңлаткан: «Менә, кияү, шушы кадәр малы белән яратып үстергән кызым сиңа. Матур гына яшәп китә алсагыз, калган өлешен дә китереп бирермен, начарга китсә, тиененә кадәр кире кайтарып алырмын», – ди. Кияүнең башына суккандай итеп әйтә бу.

Бу сүз, билгеле, кияүне уйга сала, килгән мал алдагы тормыш өчен тәгаенләнгән бит, аны югалтасы килми. Ничек инде әйбәт тормыйсың бабайның кызы белән. Бабай үзе дә кирәк әле ул.

Матбугат барын да язып барырга тырыша, әлбәттә. Мәгълүмат күп, нигәдер ничек аерылмаска кирәклеген өйрәткән рецепт кына юк. Минем бу тәкъдимем уңаеннан башкаларның фикерләрен дә ишетәсем килә. Языгыз әле. Гаилә коруга бармак аша карау бер дә дөрес гамәл түгел бит инде.

Мәгъдәнур ГАТАУЛЛИН.
Байлар Сабасы

КУНЫРДА СИБЕЛГӘН НУР

«Авылның һәр кешесе иманлы булганга эшләребез дә уң безнең», – дип сөенешә Балтач районының Куныр авылы халкы. Без мәчет ачылуга 30 ел тулуга багышланган авыл җыеныннан сокланып кайттык.

Кемнәндер ярдәм сорап утыру да ят аларга. Булганына шөкер итеп яши беләләр. Бәйрәм сәхнәсеннән яңгыраган һәр чыгышта шушы җирлекнең тырыш кешеләре, җитәкчеләре макталды. Районда беренчеләрдән булып төзелгән мәчет эшчәнлегендәге яңалыклар белән таныштык.

Балаларны, өлкәннәрне мәчеткә тарту дисеңме, дини белем алуны оештырумы, вәгазь кичәләре үткәрүме, дини чаралар уздырумы, мәчетне карап һәм тәртипләп тотумы – барысы да Тәгъзимә апа Сәгетдинова җитәкчелегендәге Люция, Әлфия, Зөлфия, Рәмзия, Миләүшә апалар кулында икән?! Кемнәрдер башлап йөрмәсә һәм инде кемнәрдер аларга иярмәсә, авылның 30дан артык баласын, алардан ике-өч тапкыр артык өлкәннәрне мәчеткә тарта алырлар идеме икән? Авылның имамы Нуретдин хәзрәт тә аларның һәр эшен хуплап тора. Тәгъзимә апаның һәр сүзе үтемле булганга, түрә-кара янына да аны йөртәләр икән. Сүзен сүз итәргә өйрәнгән, 70 яшен үтеп баручы бу авыл апасының кайда эшләп ялга чыгуы белән дә кызыксындым. Казахстанда яшәп, туган якларына кайтып төпләнгән Тәгъзимә апа чит җирләрдә санэпедстанциядә эшләгән икән. Шуңадырмы, мәчеткә өйлә намазына килгән һәркем биредәге чисталыкка игътибар итми калмагандыр. Кыш булса да, юылган тәрәзәләр, сафлык бөркелеп торучы паласлар, тәрәзә төбен тутырып утыручы шау чәчәкле гөлләр – барысы да мәчетне олылауга ишарә икәненә төшенү артык кыен булмады.

Мәктәптә 20 елдан артык әхлак дәресләре укытылып килү дә уңай нәтиҗәләрен бирә. Бүген 2–6 нчы сыйныфларда әхлак түгәрәге эшли. Дәресләрне Гөлҗамал ханым укыта. Куныр балалары белән бергә Дорга, Шода балалары да халкыбызның үткән мирасын, гореф-гадәтләрен, тарихын тырышып үзләштерәләр. Мәктәптәге балаларның 99 проценты мәчеткә йөреп дини белем алуын ишеткәч, ак көнләшү белән көнләшеп куйдым. Менә булдыралар болар!

Бәйрәмгә килгән Казанның 1000 еллыгы исемендәге югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншинга да балаларның чыгышы бик ошады. Залга мөрәҗәгать итеп: «Бу балаларны әзерләүчеләрне күрәсе килә иде», – диде ул. Залда янәдән Тәгъзимә апа җитәкчелегендә эшләүче биш апа торып баскач, берара сүзсез калды. Аптырарлык та шул: икесе сыер савучы булган, укытучы, фельдшер, социаль хезмәткәр булып эшләгәннәр дә бар алар арасында. Ялга чыккач, Балтач мәдрәсәсендә белем алып, балаларга дини белем бирүгә алынганнар.

– Без бу балаларда, аларның чыгышында матур киләчәгебезне күрәбез. Аларда бу авылның дини йөзе дә күренә. Сокланырлык хезмәт башкарасыз, – диде Ильяс хәзрәт.

Республиканың баш казые, район мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев әйтүенчә, балаларның чыгышында өлкәннәр өчен вәгазь дә, сокланырлык ихлас дини дәрес тә, эчкерсез аралашу да булды. «Инде вәгазь сөйләп тормасак та буладыр», – диде ул. Баш мөфти урынбасары Илфар хәзрәт балаларның һәр әйткән аятеннән күңелләр нечкәрүен, ихласлык, мәрхәмәт артуын әйтте.

Элеккеге күмәк хуҗалыгы җитәкчесе, хезмәт ветераны Хәмит абый Гәрәев мәчет төзелешендә эшләгән кешеләрне кайта-кайта искә алып үтте. Гади халыкны данлаган, үз авылында гадел «түрә» булган, элеккеге зират өстенә салынган амбарларны күчереп салдырган һәм тагын башка бик күп игелекле эшләр башкарган җитәкче ул.

Эшләре, кылган гамәлләре белән дә үрнәк булган әлеге ак авыл, якты авыл – Куныр турында җылы хатирәләр белән кайтыр юлга чыктык. Чарада катнашып, күпме җылылык алып таралыштык.

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ

Күкрәгенә былбыл кунган

Көнкүрешенең ни дәрәҗәдә булуына карамастан, татар җыелган мәҗлес үзәгендә җаннарны җилкендерүче гармунчы урын ала. Бу гадәтебез зур-зур калаларда да, кеп-кечкенә авылларда да бүгенгәчә яши бирә. Сугыш дәверен кичергәннәр beләдер: төбәкләрнең оста гармунчылары фронтка китеп баргач, кайгы-хәсрәт эченә чумган авылларда аз гына гармун шыгырдата башлаган малайларны, өйдән-өйгә йөртеп, күрше авылларга алып барып, барыбер музыка яңгыраталар, җыр сузалар, аннары, күңел түрендәге шик-шөбһәләрне тәмам таратып бетерер өчен, идән такталарын сыгылдырып биергә тотыналар, нәни гармунчының нечкә бармаклары тәмам хәлсезләнеп беткәнче бөтереләләр иде. Шушы елларда гармунчыларыбызның халыкка фидакарьләрчә хезмәткә алынган яңа буыны өлгереп җитте.

Татарстанның атказанган артисты Рамил Курамшин үзе сугыш дәверендә үсмәсә дә, әнә шул фидакарьләр үрнәгендә тәрбия алган музыкант иде. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләгәндә дуслары аны, яратып, «янгын сүндерүче» дип тә атадылар. Хикмәт шунда ки, филармониядәге берәр төркемдә көтелмәгән хәл чыгып, баянчы килми калса, иң беренче Рамилгә мөрәҗәгать иттеләр: «Концерт башланырга фәлән сәгать калды, баянчыбыз килә алмый, коткар, зинһар!» Аңа мөрәҗәгать итүче, әлбәттә, ышана инде: Рамил аның сүзен аяк астына салмаячак. Киләчәк. Килдеме – аның чыгышы өчен борчылмаска мөмкин, ул үз һөнәрен иң югары һөнәри дәрәҗәдә башкарачак. Әле башка иптәшләренә дә ярдәм итәчәк.

Концертлар вакытында сәхнәдән сөйләгән кыска-кыска хикәяләре – бер хәл. Ул безнең музыка дөньябыз турында матбугатта да уңышлы язмалары белән катнашты. Җөмһүриятебездә чыга торган төрле басмаларда Рамил Курамшин язган мәкаләләрне укысаң, аның эрудициясенә дә, укучылар игътибарына тәкъдим иткән кыю фикерләренә дә хәйран каласың. Музыкантның бу гамәлен бары тик туган халкын, милли сәнгатебезне олылау, аны тагын да үстерергә тырышу хисе белән генә аңлатырга мөмкин.

Рамил Курамшин күпкырлы талант иясе иде. Моннан ун еллар элек аның җырга осталыгы да ачылып китте. Ихтимал, ул үзалдына яшьли үк җырлагандыр инде. Соңрак халык алдында да җырлый башлады. Аның моңлы тавышы, баянда уйнавы кебек үк, җанга үтеп керә, күңелне кузгата иде. Бу моң чишмәсенең башлангычы кайда һәм ул аһәңнәрен кайдан алган соң? Еллар буе кочагыннан баянын төшермәгән музыкант бу яраткан һөнәренә генә риза булмыйча, нигә җыр да сузып җибәрде соң әле?

Хикмәте әллә кайда, тирәндә түгелдер кебек. Рамил озак еллар буена Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, милләтебезнең мактанычы, халкыбызның кадерле җырчысы Илһам Шакиров белән бергә эшләде. Күпме юллар бергә узылган, ничәмә-ничә шәһәр һәм авыл сәхнәләрендә уртак уңышларга ирешелгән, алкышларга баш иелгән. Илһам җыр суза, Рамил, аның күкрәгеннән ургып чыккан моңнарны тагын да куәтләбрәк, баянын сыздыра. Күрәсең, тора-бара аңа җырчының чыгышы шул кадәр көчле тәэсир итә ки, Рамил үзе дә көйләп җибәрә. Җырлый башлый һәм уңышка да ирешә! Әле нинди җырны башкара бит! Татар халкының иң кадерле хәзинәсен, милләтнең бәгыреннән саркылган моңын – «Кара урман»ны суза ул! Илһам Шакиров үзе башкарган җыр бит югыйсә. Инде берәү булса, җиңелрәк әсәрне сайлар иде. Юк, Рамил бервакытта да җиңел юлны сайламады – талның юанын бөгәргә күнеккән ул. Һәм бу юлы да теләгенә ирешкән. Моңа ничек сокланмыйсың?!

Рамил Курамшинның музыка дөньясын аңлаучыларны сокландырырлык ачышлары байтак. Әйтик, берничә ел элек ул Казанның гармунчыларын һәм баянчыларын җыеп, аерым бер төркем оештырды. Химиклар мәдәният сараенда уңышлы башланып киткән бу эш шулай ук куанычлы нәтиҗәләргә китерде. Рамил өйрәткән баянчылар чыгышын тыңлап туймаслык иде! Өстәвенә бу яңа талпынышы аңа икенче бер игелеккә юл ача. Казан тамашачысы шагыйрь Нажар Нәҗминең иҗат кичәсендә, Камал театры сәхнәсендә «Саз» ансамбле башкаруында «Синә тагын мин бер киләм әле» (Рим Хәсәнов көе) әсәрен ишетеп аптырап калды: «Саз»ның җитәкчесе, талантлы баянчы Рифкать Гомәров вафат лабаса. Баксаң, хезмәттәше Рифкатьнең кадерле «Саз» ансамблен Рамил кабаттан «терелткән» икән. Бу инде – музыкантыбызның талантын гына түгел, кешелеклелеген дә, дуслыкка тугрылыгын да раслый торган күркәм сыйфат. Ансамбльнең репертуарындагы яңа җырларның көйләрен Рамил Курамшин үзе иҗат иткән иде.

Баянда уйнауның тирән серләрен, бу уен коралында башкарылырга тиешле әсәрләрнең максатын-омтылышын бөтен җаны белән аңлаган хәлдә, аны баянчылар өчен тәкъдим ителгән әзер «байлык» кына канәгатьләндерми башлый. Шуңа да Рамил акрын-акрын көйләр иҗат итә. Башта халык көйләрен эшкәртеп карый – уңышка ирешә. Аннары, тәвәккәлләп, баянда уйнау өчен шактый катлаулы әсәрләр иҗат итәргә тотына: скеоно, концерт өчен пьеса, халык уен кораллары оркестрына кушылып баянда уйнала торган концертино... Аның бу әсәрләре – училищеларда, консерваториядә, музыка мәктәпләрендә укучы баянчылар өчен алыштыргысыз кулланма. Алар нәкъ менә профессиональ баянчы тарафыннан иҗат ителгәнлектән, максатының ачыклыгы, тыңлаучыга аңлаешлылыгы һәм техник яктан төзеклеге-сафлыгы белән аерылып тора. Бу күркәм сыйфатлар Рамил Курамшин чыгарган җырларга да хас: алар, беренчедән, башкаларга охшамаган – яңача, Рамилчә яңгырыйлар, бу җырларга елак авазлар ят, әмма алар моңлы, халыкчан.

Шулай да, нинди генә киңлекләрдә иҗат итсә дә, Рамил Курамшинның төп һөнәре, талантының таянычы һәм хисләренең иң ачык чагылышы аның баянына барып тоташты. Зур концерт Рамилнең баяныннан башка сирәк узды. Сәхнәләребездә без аны яраткан җырчыларыбыз белән дә, баянында үз әсәрләрен уйнаганда да хуплап каршыладык, алкышлап озаттык.

Рамил Курамшинны үз ишләре дә, әдәбият-сәнгать әһелләре дә хөрмәт итте. Ул язучылар, журналистлар, композиторлар, рәссамнар, хәтта сәясәтчеләр арасында да үз кешедән саналды, чөнки бу шәхес һәрьяктан әзерлекле. Аның белән теләсә кайсы мәсьәлә хакында тирәннән алдырып әңгәмә корырга, бәхәс куертырга мөмкин иде. «Иде» дип әйтү дөрес тә булмас иде. Ул һәрвакыт арабызда яши. Без аны сагынып, юксынып искә алабыз, баянда уйнавын, җырлавын тыңлап хозурланабыз.

Клара ТАҖИЕВА

МИН-МИНЛЕК ИЛНЕ ҖИМЕРӘ

ИДЕГӘЙ ДАСТАНЫ ТАТАР ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНӘ КАЙТТЫ

tinchurinteatr.ru

Премьера

Күптән көтелгән премьера! 500 еллык тарихы булган «Идегәй» татар халык дастаны, ниһаять, Тинчурин театры сәхнәсенә күтәрелде. Аны театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов сәхнәләштерде.

Спектакль ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган. Аның тарихи, мәдәни әһәмиятен арттырган тагын бер вакыйга бар: «Идегәй» татар дөньясында игълан ителгән «Дастаннар елы»нда дөнья күрде. Журналистлар белән очрашуда Туфан Имаметдинов «Идегәй»не сәхнәгә куярга алынуын әсәрнең милли, әдәби, тарихи актуальлеге белән аңлатты.

– «Идегәй» дастаны тамашачыларда әдәби телебезгә, рухи мирасыбызга, милли мәдәниятебезгә ихтирамны арттырыр дигән өметем зур. Ул Тинчурин театрында яңалык та, борылыш та булачак, – дигән иде режиссер.

Сүз уңаеннан, әлеге борылыш бик күп детальләрдә сизелде. Әйтик, спектакль тәмамлангач, актерлар кире сәхнәгә чыкканда, экранда «Баш июләр булмаячак» дигән язу пәйда булды. Театр администрациясе тараткан чәчәкләрне дә яшь буын актерлар тамашачыга ташлады. Ясалмалык булмаячак дигән сүз иде булса кирәк.

«Идегәй» – татар халкының иң танылган тарихи эпосларының берсе. Ул Алтын Урда таркалу чорында булган тарихи вакыйгаларга нигезләнгән. Әсәрнең сюжеты, нигездә, шәхси мөнәсәбәтләр турында сөйли кебек. Сурәтләнгән вакыйгаларда Алтын Урда һәм төрки халыкларның язмышында хәлиткеч роль уйнаган тарихи шәхесләр катнаша.

Төп герой – Идегәй ролен яшь актер һәм режиссер Илнур Гарифуллин башкарды. Шаһтимер ролендә – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Зөфәр Харисов. Туктамыш хан һәм Йәникә рольләрендә Татарстанның атказанган артистлары Ирек Хафизов һәм Гүзәл Гайнуллина иде.

Батырлык, туган җиргә мәхәббәт, дошманнарга нәфрәт, дуслык һәм үз-үзеңне корбан итү, намуслылык һәм гаделлеккә дан җырлау. «Идегәй»нең төп мотивлары әнә шул. Спектакльдәге геройлар арасында каршылык тиз арада төп конфликтка әверелә. Тик аның асылында нәрсә ята соң?

Идегәй – халык таныган каһарман, гаделлеге, зирәклеге белән хөрмәт казанган хөкемдар. Спектакльдә аның эш-гамәлләрен, әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтен, хыял-омтылышларын, каршылыклы характерын ачуга киң урын бирелә. Әйтергә кирәк, килеш-килбәте белән Илнур Гарифуллин әлеге роль өчен уңышлы сайланган.

Шунысы да бар: Идегәй – Илнур Гарифуллинның татар сәхнәсендә татар телендә уйнаган беренче роле.

– «Идегәй»гә алынган беренче вакытларда бик авыр булды. Миңа Зөфәр абый Харисов, артистлар, режиссер бик булышты. 20 ел татар телендә сөйләшмәдем. Хәзер мин өйрәнәм, үз тамырларыма, телемә кире кайтам, – ди Илнур. – Безнең спектакльдәге Идегәй – күбрәк әдәби персонаж. Монда ул герой, илдә тәртип урнаштырган кеше итеп күрсәтелгән, тарихта Идегәй – революционер, начар кеше. Тик шулай да ул – көчле, ышандыра торган һәм тансык персонаж. Идегәй туган мизгелдә күп кан түгелә. Аңа сугышчы юлыннан башкасы язмаган да кебек. Гомере буе алданганын белгәч, ул кача, халыкка кирәк чагында иленә кире кайта. Тик дастанда халык өчен якты киләчәк юк. Алтын Урда таркала. Идегәй һәм башкалар өчен дә үлем һәм җир генә кала. Туктамыш һәм Шаһтимер Туктамыш дәүләте символы Төкле аяк (кош) өчен сугыша башлый. Вак-төяк әйбер сыман, тик шуның аркасында күпме кан коела. Кеше үз гомерен ниндидер максат өчен бирергә мәҗбүр була. Бөтен дөньяда сугышлар барганда, кан коелганда мондый әсәрләр гел актуаль булачак.

Татарстан Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Миркасыйм Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев үзенең жанрына күрә дастан яхшы күрсәтелгән һәм ачылган дигән фикердә:

– Әлбәттә, бу әсәр татар халкы өчен бик мөһим. «Идегәй» – илебезнең җимерелүендә төп рольне уйнаган шәхес. Ул катлаулы да, әмма халык шундый шәхесләр аша тарихка бәя бирә, анализлый, карый. Идегәй – бәхетсез герой. Алтын Урданы күтәрергә тырыша, тик үзе күтәргән бөтен ханнар, хәтта уллары да аңа каршы чыга. Дастанда «Идел туңса, кем кичмәс, Идегәй үлсә, кем алмас?» дигән сүзләр бар. Илне җимереп, бәхет тапмаган Идегәй. Аның үлүен көткәннәр. Нәселе белән сугыша-сугыша, Алтын Урда да җимерелә, – ди Илнур Миргалиев. – Миңа калса, спектакльдә Аксак Тимер ачылып бетмәгән. Шәһәрләрне Туктамыш хан җимергән, Идегәй яклаган кебек килеп чыккан. Тарихи чыганаклар буенча, шәһәрләрне Аксак Тимер җимергән, Идегәй аңа юл күрсәтеп килгән хәтта. Тимернең Алтын Урдада халыкны кыруын, шәһәрләрне җимерүен күргәннән соң, аңардан качып китә. Монда, бәлки, күбрәк Шаһтимер, Аксак Тимер образларын тагын да ачарга кирәк булгандыр? Гомумән алганда, спектакль яхшы килеп чыккан. Куелышы, артистларның уйнавы ошады. Татар халкы, аны карап, дастаннар белән кызыксынып, алар аша чын тарихыбызны өйрәнер дигән өметтә калам.

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров та спектакльдә татарның фаҗигале тарихы ачылган дип саный.

– Татар халкының дастаннары бик күп һәм аларны төрле формада күрсәтергә була. Монда «Идегәй» ничек бар, ничек язылган, шулай куелган. Минемчә, чын дастан белән шулай курыкмыйча эшләргә кирәк. Чын әсәрнең үзен күрсәтү ул – бик зур әйбер. Автор тарафыннан эшләнгән түгел, ә режиссер кушып, әсәрнең чын мәгънәсен табарга тырышу. Юлларын табу – анысы икенче. Бәлки, шау-шусыз да ышандырырга мөмкиндер. Заманында без Юныс Сафиуллин инсценировкасы буенча куйдык. Аерма бик зур, әлбәттә. Ничек булса да, биредә Идегәйнең язмышы фаҗигале итеп күрсәтелгән һәм ул шулай булырга тиеш тә. Аксак Тимер гаскәрләре Идегәй аркасында бөтен җирне җимереп, кырып баралар. Идегәй үзенең бөеклеген күрсәтергә теләп, үз дәүләтен җимерә. Бу – безнең фаҗигале язмыш.

Ләйсән САФИНА

ЯНТЫК ЛОМОНОСОВЫ

Шәхесләребез

76 яшьлек инженер Рафаэль Кушминны күптән түгел пионерга алганнар. Хәзер аның ике кызыл галстугы бар. Питрәч районының Шәле мәктәбе беренче медалистын әнә шулай зурлаган. Рафаэль абый исә очрашуда укучыларга белем һәм кеше кадере, татар мәктәбендә укыганнарның тормышта югалып калмавы турында сөйләгән.

Юл газабы

Лаеш районының Янтык авылы егете Рафаэль Кушмин Шәле мәктәбенә очраклы гына килеп эләккән. Сугыштан соңгы авыр заманалар үзенекен иткән. Ул вакытта укуга түгел, тәмле ашатканга кызыгып килгән алар. Мәктәптә исә аның көндәлектәге «4ле», «5ле»ләренә игътибар иткәннәр. 9–10 сыйныфларда 17 чакрым араны кышын чаңгыда, башка вакытта велосипедта үткән ул. Ломоносов кебек җәяү барган чаклары да булмаган түгел. Бу урында ул мәрхүм сыйныфташы Саматны искә алды. Юл йөргәндә, төрле маҗараларга да очраганнар.

– Бервакыт яз көне Самат белән чаңгыда авылга кайтырга булдык. Басуда кар эреп бетмәгән. Авыл белән ике арада елгадан шаулап ташу ага. Кем шулай булыр дип уйлаган аны?! Авыл күренеп тора, кире Шәлегә китәсе килми. Су тездән югары, алай тирән түгел. Чаңгыны салдык та, чишенеп, бозлы суга кердек. Елганы чыгуга, җилкәгә чаңгыны салып, җылынырга дип тизрәк өйгә йөгердек, – ди Рафаэль абый Кушмин.

Биш яшьтә укый башлаган

1 нче сыйныфка укырга керүе дә башкаларныкы кебек булмый аның. 1945 елда туган беренче тапкыр мәктәпкә керүче балалар тугыз гына икән. Ставка өчен бу сан гына җитми. Бу инде – укытучының хезмәт хакы да азрак булачак дигән сүз. Шуңа күрә башлангыч сыйныф укытучысы Банат апа, Рафаэльнең укый-яза белүен ишетеп, укырга чакыра. Аны әтисенең сеңлесе укытучы Гөлсем апасы хәреф танырга өйрәткән. Кечкенә Рафаэль мәктәпкә барганчы, китапханәдәге күп кенә китапларны да укырга өлгергән. Китапханәчене аптыраткан бу хәл. Рәсемнәрен генә карамыймы икән дип, малайдан әсәрнең эчтәлеген сөйләткән ул. Күпмедер белеме бар, димәк. Шулай итеп, җиде яшьтә генә барырга тиешле малай алтыда ук укырга китә. Бу вакытта сыйныфташлары Әлифбаның «Ө» хәрефенә җиткән була инде. Бер ай да ун көн үткән бит. Дәресләрнең иң яратканы – математика.

– Ул заманда телевизор да, интернет та, телефон да юк. Китапка ябышып ята идек. Безне китап тәрбияләде, – ди Рафаэль абый.

Тормышта барысы да шома гына бармый. 12 яшьлек чагында әнисе Фатыйма дөнья куя. Гаиләдә – өч бала. Укырга барганда, әбисе Рафаэльгә атнага 1 сум акча бирә торган була. 6 нчы сыйныфта укыганда, аны колхозда учетчик итеп куялар. Кем күпме печән чапкан, урган – барысын да дәфтәргә язып бара. Ай ахырында бухгалтериягә хисап тапшыра. Рафаэль абый хәзер үзе дә: «Ул вакытта миңа ничек шул эшне ышанып тапшырганнар икән?» – дип аптырап куя.

Янтыктагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Державинда интернатта яшәп белем ала. 9 нчы сыйныфтан соң татар сыйныфын япкач, Солтан мәктәбенә китәргә туры килә. Тик монда ашау ягы такыр. Интернатта торган укучыларга бер чиләк кайнаган су кертеп утырталар да, шуның белән шул. Ашау юк. Өйдән алып килгән әйбер белән генә тамаклары туймый. Шәле мәктәбенә шул тамак хакы китергән дә инде. Анда өч мәртәбә ашатканнар.

Белем булмаса, бит кызара

Мәктәпне бер генә «4ле» белән тәмамлаган Рафаэль Кушмин Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына юл тота. Ул вакытта мәктәптән соң укырга керү бик авыр булган.

– Факультетка 150 кеше кабул итсәләр, шуның 20 проценты гына – мәктәпне тәмамлаучылар. Без кергәндә солдатлар күп иде. Аларның өстендә – солдат киеме. Без алардан алты яшькә кечерәк. Акча түләп керү дигән нәрсәне белмәдек. Татар мәктәбендә уку бервакытта да белем алырга комачауламады. Спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таптым. Чаңгы буенча институтның җыелма командасы составында төрле бәйгеләрдә ярыштык, – ди әңгәмәдәшем.

Инженер-механик белгечлеге алгач, юллама белән аны Кукмара районының Яниль училищесына җибәрәләр. Шунда 2,5 ел студентларны укыта. Сәләтен, оештыру осталыгын күреп, Кукмара районы комсомол оешмасының беренче секретаре итеп билгелиләр. Райком партиясе секретаре, өйләнсәң генә фатир бирәм, дигәч, анысына да тәвәккәлли. Йөргән кызы белән өйләнешәләр. Шуннан соң – бер ел армия хезмәте. Дипломлы егеткә хезмәттә юллар ачылып тора. Рафаэль абый башта Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләгән, аннан Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең белемен күтәрү мәктәбендә биш ел директор вазыйфасын башкарган, Мелиорация министрлыгында ике ел хезмәт куйган. Аннан Казандагы газ аппаратурасы заводының директор урынбасары итеп чакыралар. 1994 елдан заводның Чабакса авылындагы ярдәмче хуҗалыгында 12 ел совхоз директоры булып эшли. Хәзерге вакытта ул – Казандагы хосусый оешмада җир мәсьәләләре буенча әйдәп баручы инженер.

– Укымасам, белемемне күтәрмәсәм, бу урыннарда эшли алмас идем. Бервакытта да дәрәҗәләргә кызыкмадым, әмма юллар үзеннән-үзе югары урыннарга чакырып тордылар, – ди Рафаэль Кушмин. – Белемсез ерак китеп булмый. Кая барсаң да кирәк ул. Кеше белән аралашканда, төрле темаларга сөйләшәсең. Әйтер сүзе булмаган һәрвакыт читкә карап тора. Аның мәгълүматы аз икәнлеге күренеп тора. Интернетны белмәсәң дә, үзеңне башка көймәдә итеп хис итәсең. Замана таләбе бу. Шуңа күрә үземә кирәклесен өйрәндем.

Рафаэль ага бүгенге балаларның, көч түкмичә генә укып, аз гына эшләп, күп акча алырга теләвенә дә аптырый. Алма күктән төшми, барысы өчен дә тырышырга кирәк, ди. Татар мәктәбендә белем алуга карата да – үз фикере. Татар теле авыл капкасын чыкканчы гына кирәк, дип уйлаучы әти-әниләр белән килешми ул. Бу – бик ялгыш фикер. Теләк булганда, барлык каршылыкларны да җиңәргә була. Сылтау тапмаска кирәк!

Сәрия МИФТАХОВА

Пар канатлар

Кадерен белеп кенә

Якын кешеңнең кадере олыгайгач арта. Лаеш районының Атабай авылында гомер итүче Хәмидә Ибраһимова әнә шулай ди.

– Дамир минем беренче мәхәббәтем булды. Башка кешене күрмәдем дә, белмәдем дә мин. Гомерем буе иремне генә яратып яшим. Баштарак сөю хисләрен бик аңлап та бетермисең икән ул, – дип сөйли Хәмидә апа.

Аларны Казан таныштыра. Берсе – Атабай егете, икенчесе – Чирмешән районының Якты Тау авылы кызы. Дамир да, Хәмидә дә төзелешкә эшкә керәләр. Әле ул вакытта бер-берләрен белмиләр дә. Әмма бер очрашу бөтенесен хәл итә. Кашыкка салып йотарлык чибәр кызны егет күреп ала да башка ычкындырмый. Алар өйләнешәләр. Ул чакта берсенә – 20, икенчесенә 21 генә яшь була. Озак та үтми, Дамирны армиягә алалар. Хәмидә төзелештә кала. Көннәрдән беркөнне кыз янына Дамирның абыйсы килә дә аны заводка эшкә урнаштырасын әйтә. Баксаң, Дамиры авыр күтәреп эшләмәсен дип кайгырткан була. Дамир исә армиядә моряк булып хезмәт итә дә үзен диңгезгә багышлый.

– Башта кайткалап йөрде дә, аннары олы кызым Лилия тугач, без аның янына киттек. Мурманск шәһәренә барып урнаштык. Дамир бик тырыш иде ул. Яшь булуына карамастан, җитди дә, үз эшенең остасы да иде. Аны читтә яратып «маленький татарин» дип кенә йөрттеләр. 24 яшендә без яшәгән гарнизонның депутаты итеп сайлап куйдылар үзен. Ул чакта егетләр төпле акыллы булган инде. Анда бит блат дигән нәрсә юк. Мине куй, синекен куябыз, дип тә әйтмиләр. Эшеңне күрәләр дә билгелиләр иде. Ул чакта ирем белән горурланып яшәдем. Хәзер дә ирем янда чакта бар борчуым онытыла, – ди Хәмидә апа.

Мурманск шәһәрендә икенче кызлары Галия дә туа. Дамир абыйга бер хәрби конфликтта да катнашырга туры килә. Бу турыда сөйләргә дә ярамый аларга. 1,5 елдан соң эш сәфәрендә булдым дип кайтып керә. Хәбәрләшү өчен телефон да юк вакыт. Хәмидәсе сабыр гына көтә. Гомер буе сабыр итә ул. Тормышта төрле чаклар була. Күз яшьләре дә тама, әмма гаиләне саклап кала беләләр. Аның каравы бүген шул сабыр итүнең әҗерен күрә дә инде ул.

– Дамирым – бик хисле кеше. Ул кошлар тавышын тыңларга ярата. Җәйләрен озак йоклап ятмый, тизрәк урманга чыгып китә. Аннары ул беренче чәчәкләрне, беренче җиләкләрне гел үзе өзә һәм миңа алып кайта иде. Хәзер дә шулай. Мин һәм балалар дип яши. Инде оныклар да кушылды бу исемлеккә. Иң тәмлесен аларга дип саклап тота. Казанга илтеп тә бирә әле, – ди Хәмидә апа.

Читтә рәхәт булса да, туган як сагындыра. Дамир абыйга күченеп кайтулар җиңел булмаса да, алар Лаешка юл тота. Дамир абыйның туган авылы Атабайга кайтып төпләнәләр. Мишә, Чулман елгаларыннан башка яши алмаганын аңлый ул. Кайтуга, кош-корт үстерә башлыйлар. 13 ел буе ирле-хатынлы үрдәкләр, казлар саталар. Төннәрен йокламыйлар да хәтта. Күрше Башкортстан, Мари Иле, Чуашстан республикаларына кадәр барып кош-корт саталар.

– Дамир сусыз бер генә көн дә тора алмый. Монда кайтуга, балыкка йөри башлады. Әле хәзер дә иртәнге дүрттә торып чыгып китә. Кайчак, әллә йөрмисеңме, дип тә карыйм. Иң зур бәхетемнән мәхрүм итмә мине, ди. Ә безнең иң зур шатлыгыбыз – Дамир! Аның ышыгында гына шундый рәхәт, җил-яңгыр тими икән, – ди Хәмидә апа. – Ирем мине култык астына сыендырып йоклый. Иң рәхәт кочак менә кайда, дим! Картайгач була икән ул мәхәббәт! Авырган чакларым да күп. Дамир бер дә уфтанмый, мине кадерләп кенә тора. Даруны да алып кайтып бирә, табибларга да йөртә. Мин исә намаз саен бер теләктә – Аллаһы Тәгалә бәхетемне күпсенмәсен иде!

Ике кызыннан да игелек күреп яши алар. Лилияләре музыка, хезмәт дәресләрен укыта. Кул эшенә бик оста икән. Укучылары да бик яраталар, ди үзен. Башлангычта аш-су серләре белән бүлешсә, уртанчыларга тегү-бәйләүне өйрәтә икән.

– Балаларым өчен күңелем тыныч. Галия кызым да онык сөя инде хәзер. Дәррәү килеп кайтып керүләреннән дә рәхәте юк. Мин өйдә генә торгач, кем кайтса да, кунак итеп җибәрәм, – ди Хәмидә апа. – Дамир белән өйләнешүебезгә 50 ел узды. Бер караганда, күп кебек ул. Әмма безгә сизелмәде дә. Минем яшьләргә киңәшем бар: гаилә коргансыз икән, аны саклагыз. Бер-берегезне рәнҗетмәгез, кадерләп яшәгез. Яшь чак уза да китә. Ә менә олыгайгач, тиңең кирәк. Иңенә башың салырлык, авыр чакта юатучы, шатлыгыңа синнән күбрәк сөенүче кирәк. Тормышның кадерен белегез!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Дөньяның төрле почмакларында яшәүче татарлар җиде төрле гармунда уйный. Алар – тальян гармун («вятская»), «тула», «саратов», «венский», «хромка», «татар гармуны», кечкенә гармуннар («черепашка»). Проектның беренче чыгарылышын татар халкының якын дусты һәм яраткан уен коралы ТАЛЬЯН ГАРМУНга багышлыйбыз.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

АЙРАТ ХАРИСОВ:

«ТАЛЬЯННАР ТИК ЯТМАСЫН»

Тальян язмышы кем кулында? Өметлеме ул? Тальянны табын артыннан олы сәхнәгә күтәрү юллары нинди? Гармун ясау остасы, мәшһүр Зидыяр Мухаяровның укучысы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Айрат ХАРИСОВ белән әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзләдек.



:: Тальян ясау серләрен өйрәнергә теләүчеләр, сездән соң бу һөнәрне дәвам итүчеләр бармы? Яшьләр кызыксынамы?

– Яшьләр бик кызыксына дип әйтә алмыйм. Алай да, ике яшь егет килеп өйрәнеп киткән иде, инде менә үзләре тырышып эшләп яталар. Укучыларымның күбесе – өлкән яшьтәгеләр. Монда килеп өйрәнәләр дә, кайтып, үзләре эшли башлыйлар. Теләге булганнар араны ерак дип тормый – Татарстан гына түгел, башка төбәкләрдән дә килүчеләр бар. Аннан соң, зур заказлар булганда үземә генә авырга туры килә. Андый чакта ярдәм итүчеләр кирәк. Мин аларга гел әйтәм инде: «Миңа ярдәм итүегез – бер хәл, сез бит әле монда олы мәктәп узасыз, моңа башка беркайда да өйрәтмиләр», – дим. Әле менә өч айлап элек Башкортстаннан киявемне дә алып килдем.

Ләкин гармун ясау – бер әйбер, уйнаучысы кирәк аның. Татар конгрессы да, Мәдәният министрлыгы да, гармун ясагыз әле, дип еш мөрәҗәгать итә. Ярый, дәүләт заказын үтибез, ди, аннан без ясаган гармуннарны таратталар, ди. Бу бик яхшы. Ләкин күп очракта ул гармуннар мәдәният йортларында тик ята бит...

:: Уйный белүчеләр аз, ягъни?

– Булганнары да – өлкәннәр. Алары да, кызганыч, китеп бара... Татар гармунына примитив дәрәҗәдәге гармун дип карыйлар. Яшь баянчылар тальянны мәҗлесләрдә, табын янында уйнар өчен ясата. Тальян булганда, табын җанлана, диләр. Ә бит аны, Фән Вәлиәхмәтов, Айдар Фәйзрахманов, Рөстәм Вәлиев, Рәшит Мостафин, Ринат Вәлиев кебек, олы сәхнәгә чыгарырга кирәк!

Гомумән, бүген тальян язмышы – энтузиастлар кулында. Махсус программалар төзеп, сәнгать мәктәпләрендә, көллиятләрдә һәм югары уку йортларында тальянда уйнарга өйрәтә башласалар, бу хәл бераз булса да үзгәрер иде. Башкортстанны алыйк. Анда халык уен кораллары арасында иң абруйлысы – курай. Сәнгать мәктәбендә дә, уку йортларында да балаларны курайда уйнарга өйрәтәләр. Алай гына да түгел, югары белемле курайчылар әзерлиләр. Татарстанда да, ихтыярыйга калдырып түгел, бераз мәҗбүри төсмер өстәсәң, бер дә начар булмас иде.

:: Гармун ясау – керемле кәсепме?

– Гармун ясый башлаганыма 30 елдан артып китте. Элегрәк, Башкортстанда яшәгәндә, төп эшемнән буш вакытта гына ясый идем. Казанга күченгәннән бирле бары тик гармун ясау белән генә шөгыльләнәм. Билгеле, заказлар булса, яшәргә була. Шөкер, бәяләр яхшы – алучы гына булсын. Ләкин ясап, акчасын алдым да бетте түгел шул. Мин аларның язмышы өчен борчылып торам. Уйныйлармы? Тик ятмыймы гармуннарым?

Тагын шунысы бар: заказга ясау ул – күмәк эш, үзенә күрә бизнес була инде. Ә бит мин җиз телле гармуннар да ясыйм. Алары – минем гармуннар. Кызганыч, узган ел андый гармунны бары тик берне генә ясарга насыйп булды.

:: Тальянның абруен ничек күтәрергә?

– Әйткәнемчә, тальянны зур сәхнәгә күтәрергә кирәк. Осталарга гына түгел, үзешчәннәргә дә. Аларга, билгеле, ярдәм итәргә кирәк. Районнарда төрле бәйрәмнәр, конкурслар узып торса, гармунда уйнарга өйрәнүчеләр осталыкларын башкаларга күрсәтә алса, тальян күтәрелеп китәр иде. Аннан соң, ни өчен бездә гармун көйләренә биемиләр? Ә халык җырларын ни өчен тальянга кушылып җырламыйлар? Бездә халык җырын да йә баян, йә синтезаторга кушылып җырлыйлар, биюен дә шулай.

:: Тальян язмышы өметлеме?

– Ул югалырга тиеш түгел. 2023 ел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Быел ни дә булса эшләнергә тиеш, миңа калса. Мәдәният министрлыгына халык сәнгатен күтәрү юнәлешендә күбрәк эшләргә кирәк. Инструментлар тараттык та бетте түгел. Уйныйлармы, әллә тик ятамы алар – тикшерсеннәр, нинди дә булса таләпләр куйсыннар иде. Уйнамыйлар икән, уйный белә торган кешегә бүләк итәргә кирәк.

АЙРАТ ХАРИСОВ ОСТАХАНӘСЕННӘН ВИДЕОРЕПОРТАЖ

МИЛЛИ БРЕНД: ПРОБЛЕМА һӘМ ЧИШЕЛЕШ

Тальян ясау – бер мәсьәлә, уйнаучылары булсын! Бу фикерне Россия гармунчыларының «Алтын унлыгы»на керүче Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ринат МӨХЕТДИНОВ та кабатлады.

Бүген ул «Залесный» мәдәният үзәгендә «Татар гармуннары» халык ансамблен җитәкли *(фотода)*. Гармунчыларының иң өлкәненә – 87 яшь. Казанның гына түгел, башкаладан ерак булмаган районнардан килеп йөрүче яшь күңелле өлкән абыйларны тальянда һәм хромкада уйнарга өйрәтә Ринат әфәнде. «Өч дистә еллык тарихы булган ансамбльне яшәтәсе, яшь буын арасында да гармунчылар тәрбиялисе, аларга татар гармунында уйнау традицияләрен өйрәтәсе иде», – ди ул. Нәкъ шундый хыяллар белән «Залесный» мәдәният үзәге җитәкчесе **Тимур ЙОСЫПОВ** та янып йөри. Без исә, аларның икесе белән дә очрашып, татар гармунының язмышы, бу өлкәдәге төп проблемалар һәм алардан чыгу юллары турында сөйләштек.

ТӨП ПРОБЛЕМАЛАР НИДӘ?

Тальян – татарның милли бренды. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Шуңа да ул бәйрәмнәрдә генә түгел, һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга тиеш. Хәзерге вакытта тальян күбесенчә Сабан туе якынлашканда гына искә алына. Монысы – **беренче мәсьәлә.**

– Хәзерге вакытта Казанда 16 мәдәният үзәге эшли. Ләкин бары тик бездә – «Залесный»да гына гармунчылар ансамбле бар. Бер яктан караганда, бердәнбер булуыбыз белән горурлана алабыз. Әмма гармунда уйнарга теләүчеләрнең шактый булуын белә торып, бу хәл белән килешә алмыйбыз, – диде Тимур әфәнде. Монысы – **икенче мәсьәлә.**

Тальян яшьләргә кирәк түгел, дигән фикер дөреслеккә туры килми икән. Ринат абый моның киресен раслады.

– Аннан язалар, моннан язалар, ләкин мин бит – берүзем. Барысын да өйрәтеп өлгерә алмыйм. Теләк белдерүчеләр арасында яшьләрнең җитәрлек булуы бик куандыра. Өйрәтергә иде бит аларны, – диде ул. **Өченче мәсьәлә** – шушы.

Дүртенче мәсьәлә – тальянда уйнау өчен көйләр аз, репертуар бик тар.

Моннан тыш, тальянның иң гадие якынча 70 мең сум тора. Аңлашыла инде: хакы теләсә кемгә килешле түгел. Шулай итеп, **бишенче мәсьәлә** – тальянның бәясе.

– Әйтик, берәүнең бик тә тальянда уйныйсы килә. Ләкин мондый бәягә инструмент алырга мөмкинлеге юк. Үзешчән ансамбльләр белән дә шул ук хәл, – ди Ринат Мөхетдинов.

Һәм соңгысы: тальян язмышы әле дә – энтузиастлар кулында.

– Мин моны начар димим. Андый кешеләр булып торсын иде әле. Ләкин һәрнәрсәнең чиге булган кебек, энтузиастларның да стимулы бетеп китәргә мөмкин, – ди Ринат Мөхетдинов.

НИШЛӘРГӘ?

Һәр проблеманың үз чыгу юлы бар.

– **Беренчедән**, тальянны популярлаштыру дәүләт бурычы булырга тиеш. Әйткәнемчә, тальянга карата мәхәббәтне энтузиастлар гына уята алмый, – ди остаз.

Икенчедән, гармунчыларны туплап, ансамбльләр оештырырга, ә иң мөһиме – ул ансамбльләргә ярдәм итәргә кирәк. Тимур Йосыпов сүзләренчә, «Татар гармуннары» ансамбленә шәһәр мэриясе дә, Мәдәният министрлыгы да ярдәм күрсәтә. Матди яктан гына түгел, билгеле. Мәдәни чаралар булып торсын, безне чакырып торсыннар, ди ул.

Ә иң зур хыяллары һәм максатлары – Казанда **гармун үзәге** булдыру.

– Ул үзәк башкалада булырга, әмма бөтен республика өчен эшләргә тиеш. Без аны «Залесный» мәдәни үзәге базасында ачуны күз уңында тотабыз. Инде грант программасын язып, конкурска җибәрдек. Нәтиҗәләре мартта булачак. Ниятләребез чынга ашар дип өметләнәм, – диде Тимур әфәнде.

Әлеге үзәктә мөрәҗәгать иткән һәркемгә методик ярдәм күрсәтеләчәк, төрле мастер-класслар, дәресләр уздырылачак.

– Шул рәвешле яшьләребезне өйрәтә алыр идек. Аннан соң, тальянда уйный белү – бер нәрсә, дөрес итеп уйный белү – бөтенләй икенче нәрсә. Ил, дөнья күләмендә күрсәтерлек итеп уйный белергә кирәк! Оялырлык булмасын! Әлеге үзәк менә шушы максатка да хезмәт итәр иде, – ди Ринат абый.

Моннан тыш, тагын бер хыяллары бар. Татар гармунына багышланган **телевизион проект** башлап җибәрергә тели алар.

– Бер булды да бетте түгел. Мин моны фестиваль-конкурс форматында күрәм. Татарстанның төрле почмакларыннан гармунчыларны җыеп, аларга бәя биреп, тамашачыга күрсәтәсе иде. Ахырдан профессионаллар киңәшләрен биреп, мастер-класслар оештырыр иде, – ди Тимур Йосыпов.

Дүртенче мәсьәләне хәл итәр өчен борынгы көйләрне барларга, **нота җыентыклары** чыгарырга кирәк.

– Мин тальянда уйнарга өйрәнү өчен ярдәмче китап чыгардым. Үз акчама. Менә хәзер ул китапны ике тапкыр калынрак итеп чыгарырга иде. Һаман саен бер көйләрне уйнап булмый бит... – диде Ринат Мөхетдинов.

Ә тальянның бәясен «көйләү» өчен аны **зур масштабларда** җитештерергә кирәк. Бу урында әңгәмәдәшләрем 2008 елда ук ябылган Казан фабрикасын искә алды. Фабрикада ясалган гармунның бәясе ул кадәр югары булмас иде, ди алар.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ,
сәнгать белеме кандидаты,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
Казан дәүләт консерваториясе доценты

Татар музыкасының Европа тәэсирендәге үсеше XIX гасырның уртасыннан башланган дип чамаларга була һәм ул Яңа тарихи вакытка бәйле. Бу чорда Яңа заман татар милли музыка мәдәнияте формалаша башлый. Аның үсешенә иң нык йогынты ясаган музыка коралының берсе – гармун.

Гармун татар мәдәниятенә XIX гасырның икенче яртысында үтеп керә. Сүз уңаеннан, гармунның беренче кулланылышы турында Мәхмүт Нигъмәтҗанов язып чыкты. Ул галим этнограф Петр Пашинонның татар авыллары турындагы истәлекләреннән файдалана: *«Кайвакыт, аеруча кичкә таба, инеш янында гармун уйнап көйләгән татар җыры яңгырый... болар боектыргыч һәм моңсу тәэсир калдыра. Шушындый ук күренешле берничә авылны үтеп киткәннән соң, монда тормыш та юк, күңел ачу да юк икән дип әйтергә генә кала...»* Бу тасвирламадан күренгәнчә, 1860 нчы еллар башына ук гармун инде татар авылының көнкүрешенә кергән булган.

Әмма гармунга кадәр йөз ел элек тә татарлар фисгармония коралы белән дә яхшы таныш булганнар, чөнки әле хәзерге заманга кадәр кайбер этник төркемнәрдә татарлар гармунны әле һаман да әргән дип атыйлар. Бу күренеш татарларның гармунга кадәр фисгармония белән дә яхшы таныш булуларын исбатлый. Шуңа күрә олы яшьтәге кешеләр үзләре күнеккәнчә гармунны әргән дип атасалар да, яшьрәк буын инде гармун сүзен куллана.

Гармун татар мәдәниятенә җиңел генә кергән дию дә дөрес булмас. Кадимчелек заманында суфи-дәрвишләр кулланган һәм Габделҗаббар Кандалый, Габдерәхим Утыз-Имәни үз әсәрләрендә искә алган: дәф, думбра, танбур, нәй кебек музыка коралларына күнеккән дини авыл картлары, әлбәттә, Европадан кергән «кяфер» саналган гармунга катгый рәвештә каршы чыканнар. Бу турыда күп чыганакларда язылды. Бу хакта Фәйзулла Туишев биографиясеннән дә укып белеп була. Әмма җәдитчелекне алга сөргән яшьләр җиңеп чыга һәм гармун татар музыка сәнгатендә үз урынын таба.

> Татарлар арасында иң күп кулланылган гармун Ливны каласында барлыкка килгән **Итальян (тальян)** ливен тибындагы гармун була. Аның уң як клавиатурасы диатоник төзелешкә туры килә һәм татарлар арасында аеруча популярлык казана. Сул кул клавиатурасын халык күпчелек очракта «бака ягы» дип атый. Бу як татар халык көйләре үзенчәлегенә туры китереп үзгәртелеп ясала торган була.

Сул як «бака» клавиатурасында гармун күреген сузганда – соль-мажор, кысканда ре-мажор аккорды яңгырый. Тальян гармуннарны күпләп җитештерү Нократ (Вятка) губернасында оештырыла, аны шулай ук Казанда да ясыйлар.

Татарлар өчен махсус тальян гармуннар ясау буенча дан-шөһрәт казанган осталар булып **Вараксиннар династиясе** танылa.

Бу династия башында Нократ губернасында туып иҗат иткән танылган гармун остасы крестьян-эшкуар Дмитрий Иванович Вараксин тора. Аның улы Михаил Дмитриевич (1892–1978) – ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, гармун остасы, татарлар тарафыннан милли музыка коралы буларак кабул ителгән «вараксин» гармунын булдыручыларның берсе. Вятка губернасы Макарьевский өязенең Вараксы авылында туа. Ул Гражданнар сугышында катнаша һәм 1920 нче елларда «Кызыл партизан» промкооперациясенең Ленинград артелендә гармун остасы булып эшли, 1930 нчы еллар башында Казанга килә һәм күренекле гармунчы-виртуоз Фәйзулла Туишев белән хезмәттәшлек итә башлый. Алар Вологда шәһәреннән килгән һәм Казан каласы гармун осталары А. Сметанин, А. Тараканов, В. Кожемякин, С. Глухов һ.б. белән гармун ясау һәм ремонтлау буенча артель оештыралар. Шулай итеп 1934 елда Казанда гармун фабрикасына нигез салалар.

> Бу инструментның халык көнкүрешендә популярлык казануы беренче чиратта гармунның тавышы тулы һәм көчле булып яңгыравына бәйле. Шулай ук коралны үзләштерү җиңел булу һәм аның портатив булуы да халыкка бик ошый.

Татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә йөзләгән гармун ясаучы осталар барлыкка килә, чөнки гармун сатып алучылар бик күп була. Тора-бара вараксин тибындагы гармуннан тыш, татарлар арасында Саратов гармуны, ике рәтле гармун, төрле кечкенә концерт гармуннарында уйнаучылар да күбәя. Атаклы гармунчылардан Татарстанның халык артисты **Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккинин, Гали Җәмлиханов** тарафыннан башкарылган көйләр төрле концертларда һәм радио, телевидение тапшырулары аша даими яңгырап, ишетелеп тордылар. Алар башкарган музыкаль әсәрләр бу сәнгать төренең классик үрнәкләре булып кабул ителә.

Бу – кызык!

- Тальянга кыңгырауларны беренче тапкыр татар осталары куйган.
- «Тальян гармун» атамасы XIX гасыр ахырында барлыкка килә.
- Салих Сәйдәшев, замандашлары сөйләве буенча, гармунда бик яхшы уйнаган. Аның уйнавын Габдулла Тукай да тыңларга яраткан дигән хатирәләр бар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 213

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+